ҮЗЕБЕЗНЕҢ ОЯ

«Йорт казы акыллырак та, тәмлерәк тә», – ди кошчылар

> 5

ҮПКӘЛЕ ТУЙ

Чыгарылыш кичәләре укучылар һәм әти-әниләрне икегә бүлә

> 15

КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН

«Бөекләр эзеннән» сәхифәсендә Исламия Мәхмүтованы искә алдык

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 61 (28834) | Җомга | 29 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КИТМИБЕЗ!

ТАТАРСТАНДА КАЙДА ЯЛ ИТӘРГӘ?

Бирәм, дисәләр дә, алырлык түгел. Чит илләргә тур бәяләрен башкача тасвирлап булмый кебек. Гадәттәгечә, җәйге ял сезонына якынлашкан саен, алар ай үсәсен көн үсә башлый. Ә бүгенге вазгыятьтә бигрәк тә. Шулай булгач, үзебездә – Татарстанда ял итү юлларын барлыйк әле. Алар шундый күп һәм төрле бит!

> 16

Ишетми калмагыз

Тиздән пособиеләрне, пенсия һәм бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттыру турында карар кабул ителәчәк. Россия Президенты Владимир Путин Закон чыгаручылар советы әгъзалары белән очрашуда шулай дип белдергән. Дәүләт башлыгы басым ясап әйткәнчә, соңгы ике ай эчендә санкцияләргә каршы чаралар җыелмасы, дистәләрчә мөһим закон һәм закон актлары кабул ителгән. «Бу эшне башкару өчен кирәкле барлык механизмнарны җентекләп эшләүне сорыйм», – дигән Президент.

Татарстан төзелеш материалларының барлык төрләре белән тәэмин ителгән. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев белдерүенчә, хәзер – торак йортлар төзүнең кызган чоры. Шуңа күрә завод складларында төзелеш материаллары запасы юк диярлек. Әмма бу товар кытлыгын аңлатмый. Аны тиз сатып алалар – бары шул гына.

Министр урынбасары сүзләренә караганда, Татарстанда төзелеш материалларын җитештерү эше бик әйбәт җайга салынган. Республика, үзен тәэмин итү белән беррәттән, аларны башка төбәкләргә дә җибәрә. Шул ук вакытта, Гыймаев билгеләп үткәнчә, инженерлык җиһазларына бәйле кайбер проблемалар бар. Мәсәлән, республикада лифтлар җитештерелми. Бу хәлдән чыгу өчен, Россия җитештерүчеләре, аерым алганда, Щербинка лифтлар эшләү заводы белән тыгызрак хезмәттәшлекне җайга салу күздә тотыла.

Татарстанда яшәүчеләр 15 апрельдән 30 майга кадәр киләсе елда беренче чиратта төзекләндерелергә тиешле җәмәгать урыннарын билгеләү мөмкинлегенә ия. Парк-сквер һәм яр буйларыннан тыш, 2023 елда «Безнең ишегалды» Президент программасы буенча өстенлекле тәртиптә яңартылачак ишегаллары өчен дә тавыш бирергә мөмкин. Сораштыруда республикадан 115 меңнән күбрәк кеше катнашкан инде. Шуның 66 меңнән артыграгы киләсе елда тәртипкә салу өчен ишегалларын сайлап алган. Тавыш бирүдә әлегә Казаннан – 20 мең чамасы, Чаллыдан – 15 мең, Әлмәттән – 7 мең һәм Түбән Кама районыннан 6 мең кеше катнашкан. Ютазы, Тәтеш һәм Теләче районнарында яшәүчеләр дә бик теләп тавыш бирә.

Сүз уңаеннан, быел 14 яшьтән зуррак үсмерләр дә сораштыруда катнаша ала.

Май аенда Россиядә җылы һава торышы көтелә. Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд илнең 60–65 процент өлешендә айлык уртача температураның нормадан югарырак булачагын белдерде. Идел буе төбәге дә шундыйлар исемлегенә керә. Күпчелек урыннарда явым-төшем норма чикләрендә тирбәләчәк. Бары тик илнең Төньяк Себер һәм төньяк-көнчыгыш өлешләрендә генә яңгырларның азрак булуы фаразлана.

Моңа кадәр КФУ Экология һәм табигатьтән файдалану институты белгече Тимур Әүхәдиев хәбәр иткәнчә, инде 20 май тирәләрендә үк Татарстанда җәй җитәргә мөмкин. Бу чорда һава температурасының нормадан чама белән 1 градуска югарырак булуы көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Район эзтабарлары Волгоград өлкәсенә китте. Алар Бөек Ватан сугышы чорында яу кырында ятып калган сугышчыларның сөякләрен табып җирләү нияте белән изге эшкә юл тотты. 30 кешелек төркемдә Зәйнең политехник колледж студентлары, яшьләр эшләре идарәсе белгечләре бар. Алар 9 Майга кадәр «Гвардия» эзтабарлар отряды җитәкчесе Виктор Никифоров, «Сугышчан бердәмлек» иҗтимагый хәрәкәте әйдәп баручысы Сергей Хватков җитәкчелегендә казу эшләрендә катнашачак.
(«Зәй офыклары»)

Түбән Кама

Быел шәһәр һәм район җирлегендә юлларны төзекләндерүгә 1 млрд 955 млн сум акча сарыф итәргә ниятлиләр. Бу эш шәһәрдә, Борок, Югары Чаллы, Актүбә, Сухрау, Каенлы, Олы Афанас авылларында, Кама Аланы бистәсендә, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлының Ширәмәт авылы янындагы өлешендә башкарылачак. «Шуңа да карамастан, шәһәр һәм районда төзекләндерәсе юллар бик күп әле. Шикаятьләр күп килә. Әлбәттә, бер ел эчендә барысын да эшләп бетерү мөмкин түгел. Шәһәр җирлегенә генә дә 15 миллиард тирәсе акча кирәк», – ди район башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин.
(e-nkama.ru)

Әлки

«Хузангай» хуҗалыгында ат заводы ачарга җыеналар. «Фермабызда Орел токымлы 32 бия һәм өч айгыр бар. Узган ел – аларның җидесе, быел 15е колынлады. Токымлы атлар Россиянең танылган заводларыннан сатып алынды. Ә айгырларыбыз – зур ярышларда катнашып, призлы урыннар алган хайваннар», – ди атлар фермасы мөдире Марат Гобәйдуллин. Атларның биологик материалларын Рязаньдагы ДНК-тикшерүләр үзәгенә җибәргәннәр. Шул рәвешле, атларның токымын рәсмиләштерәчәкләр. Заводның төп эшчәнлеге токымлы атлар үрчетү булачак. Аларны тәрбияләп, ярышка әзерләү, чабышкылар сату максаты да бар.
(«Әлки хәбәрләре»)

Балтач

Район үзәгендә чернобыльчеләр истәлегенә һәйкәл ачылды. Моннан 36 ел элек булган фаҗигинең зыянын киметү эшләрендә Балтачтан 26 кеше катнашкан, хәзерге көндә аларның 16сы исән. Араларында бердәнбер хатын-кыз Флера апа Латыйпова да бар. Якташларыбыз үзләренең сәламәтлекләре һәм гомерләре бәрабәренә кешелек дөньясын бик көчле радиоактив нурланыштан коткарганнар. Алар барысы да үзләренең һөнәри һәм гражданлык бурычларын намус белән үтәп, зарарлы радиоактив матдәләр таралуны булдырмый калганнар.
(«Хезмәт»)

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ЮЛЛАР АЧЫК

Максат – файдалы элемтәләрне киңәйтү. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мьянмага эш сәфәре кылды. Файда һәм табыш китердәй тармаклар, яңа мөмкинлекләр – республика җитәкчесе Көньяк-Көнчыгыш Азия дәүләтендә шулар хакында сөйләште.

Иң элек Рөстәм Миңнеханов Мьянманың инвестицияләр һәм тышкы икътисади багланышлар министры У Аун Найн белән очрашты. Татарстан предприятиеләренә кабул итүче як оештырган «түгәрәк өстәл» барышында үзләре турында сөйләргә мөмкинлек булды. Сүз уңаеннан, Президент җитәкчелегендәге делегациядә республиканың сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов, «КамАЗ» җәмгыяте генераль директоры Сергей Когогин, «Казан вертолет заводы», «Эйдос-Медицина» оешмасы, «Казан май комбинаты» җәмгыяте вәкилләре бар иде.

Татарстан Президенты республиканың икътисади һәм сәнәгать өлкәсендәге уңышлары турында сөйләде, хезмәттәшлек өчен ачык булган юнәлешләрне барлады.

– Татарстанның нефть химиясе, судно, машина төзелеше тармаклары, җитештерү процессларын автоматлаштыру, сәламәтлек саклау, медицина продукциясе җитештерү һәм фармацевтика препаратлары белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлегебезне киңәйтү өчен мөмкинлек бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Тагын бер мөһим юнәлеш – цифрлаштыру. Татарстанның бу өлкәдә дә уртаклашыр тәҗрибәсе шактый. Шуңа да Мьянма өчен бу тармакның кызыклы булуын әйтте Президент.

Кабул итүче як министры исә тәкъдим ителгән юнәлешләрдә хезмәттәшлекне оештырырга әзер булуын әйтте. «Татарстан Россиянең иң уңышлы төбәкләреннән санала. Без сезнең белән хезмәттәшлеккә шат булыр идек. Бергәләп эшләрлек күп юнәлешләр күрәбез», – диде У Аун Найн.

Аерым алганда, Мьянма вәкилләре Татарстаннан ашламалар китертү, ә республикага дөге җибәрү юнәлешендә хезмәттәшлекне арттыру ниятен белдерде. Татарстан Президенты шундый ук

tatarstan.ru

килешүне «КамАЗ» җәмгыяте белән имзаларга кирәклегенә игътибар юнәлтте. Июнь аена тәкъдимне әзерләп бетерергә тиешләр.

> Санлы мәгълүматларга килгәндә, Татарстан белән Мьянма арасындагы товар әйләнеше сизелерлек үсештә. 2016 елда үзара сәүдә күрсәткече нибары 1,6 мең доллар гына булса, соңгы өч елда вазгыять уңай якка борылыш алган. 2019 елда – 221 мең, 2020 елда – 237 мең, 2021 елда 379 мең долларлык сәүдә оештырылган.

Соңрак республика җитәкчесе Мьянманың Дәүләт Административ советы рәисе, Премьер-министр, Мьянма Союз Республикасының Кораллы көчләре баш командующие, өлкән генерал Мин Аун Хлайн белән очрашуда катнашты.

– Мьянма – Россиянең Азия-Тын океан төбәгендә һәм халыкара аренада якын һәм ышанычлы хезмәттәше. Безнең илләр арасында элемтәләр күпьеллык тарихка ия – 2023 елның гыйнварында без Россия – Мьянма мөнәсәбәтләре урнашуга 75 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез, – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Президент Мьянма вәкилләрен Казанда котелачәк зур чараларга кунак итеп тә чакырды. Сүз «Россия – ислам дөньясы» икътисади саммиты, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар турында бара.

Генерал Мин Аун Хлайн исә үзенең Казанга 2021 елдагы сәфәрен искә алды. Шул чордан башлап ике дәүләт арасында уңай үзгәрешләр башланганын әйтте.

– Татарстанда чакта мин сездәге химия сәнәгате, туризм тармагы үсеш алуын билгеләп үттем. Медицина җиһазларын җитештерү өлкәсендә мөмкинлекләр бар. Сәнәгать өлкәсе дигәннән, мин КамАЗда булдым. Үз күзләрем белән сезнең завод мөмкинлекләрен күргәч, инженерларга шул хакта сөйләдем. Бу юнәлештә хезмәттәшлек итеп булыр иде, – диде ул.

Моннан тыш Мин Аун Хлайн нефть тармагына бәйле мәсьәләне күтәрде. Мьянмада «кара алтын»лы урыннар бар. Әмма аны эшкәртү эше җайга салынмаган. Татарстан исә бу юнәлештә ярдәмче булыр иде дигән фикердә ул.

Очрашу вакытында Татарстан югары уку йортларында белем алырга теләүче Мьянма халкы өчен квотаны арттыру кирәклеге дә әйтелде.

БЕРДӘМЛЕК ЧАКРЫМНАРЫ

Дөньялар тыныч булсын! Әнә шундый теләк белән Владивостоктан юлга чыккан автомобильчеләр Казанга килеп җитте.

Россиянең Бәйсез профсоюзлар федерациясе тарафыннан оештырылган автойөреш «Тынычлык, хезмәт, май өчен!», «Нацизмсыз дөнья өчен!» лозунглары белән уза. 12 апрельдә юлга чыккан катнашучылар ике дистәгә якын шәһәр аша узып, Казанга килеп җиттеләр. Тынычлык хакына юлга чыккан сәяхәтчеләрне Татарстан башкаласында йөзләгән кеше каршы алды.

– Бөек Ватан сугышында бабаларыбызның Җиңүе аркасында, без «нацизм» сүзен бик озак вакыт ишетмәдек. Тыныч һәм тату яшәдек. Бүген безнең митинг «Нацизмсыз дөнья өчен!» девизы астында уза. Бу очрашуыбыз махсус операциядә катнашучы гаскәрләребезгә көч бирсен иде. Татарстан һәм бөтен Россия әлеге автойөрешкә теләктәшлек күрсәтә. Бердәмлегебез, көчебез республика һәм илебез үсешенә зур өлеш кертсен иде, – диде Татарстанның Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева.

Россиянең Бәйсез профсоюзлар федерациясе рәисе урынбасары, Бөтенроссия профсоюзлар автойөреше җитәкчесе Александр Шершуков җыелган бар халыкка рәхмәт әйтте.

– Монда кемнеңдер кушуы буенча түгел, ә үз карашлары булган, Россиянең Кораллы көчләрен һәм Президентыбызны хуплаган кешеләр җыелды. Бүген илебез катлаулы хәлдә. Безгә каршы икътисади санкцияләр кертеп, социаль киеренкелек китереп чыгарырга тырышалар. Россияне моңарчы да хәрби һәм икътисади юл белән юк итәргә омтылдылар. Без һәрвакыт халыкның бердәмлеге ярдәмендә җиңеп чыктык һәм алга таба да җиңеп чыгачакбыз, – диде ул.

Казанда автоколоннага тагын 7 машина кушылды. Алар Түбән Новгород аша Мәскәүгә юл тотачак. 1 Май – Хезмәт ияләре теләктәшлеге көнендә катнашучыларны Кызыл мәйданда каршы алачаклар. Ә 9 Майда автосәяхәтчеләрне Волгоградта көтәләр.

Ләйсән САФИНА

ЯЛ ӨЧЕН ЭШЛИСЕ БАР

Россия төбәкләренә балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм кирәк. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Закон чыгаручылар советы Президиумының Санкт-Петербургта узган утырышында әнә шул фикерне җиткерде. Россия парламентаризмы көне уңаеннан узган җыелышта балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләләре турында сөйләштеләр.

Фәрит Мөхәммәтшин утырышта республикадагы тәҗрибә турында сөйләде. «2009 елда Татарстан Дәүләт Советы балаларның җәйге ялын оештыру системасын камилләштерүне тәкъдим итте. Татарстан Президенты ярдәмендә дүртенче ел рәттән лагерьларны капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү буенча «Җәй – балаларга» программасы гамәлгә ашырыла. 2022 елда 22 лагерьны ремонтлау һәм төзү планлаштырыла, финанслау күләме 1 млрд сумнан артык тәшкил итәчәк», – диде парламент спикеры.

Аның сүзләренә караганда, мондый зур эшләрне башкарганда, мәсьәләнең хокукый ягын кайгыртырга кирәк. Бу – федераль законнарны камилләштерүгә дә кагыла. Балаларның иминлеге мәсьәләләре аерым игътибар таләп итә. Татарстан Дәүләт Советы федераль Урман кодексына үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә дә әзер. Республика закон чыгаручылары фикеренчә, балаларны савыктыру лагерьлары өчен урман аланнарында капиталь корылмалар төзүне рөхсәт итәргә кирәк. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, балаларның иминлеге һәм табигатьне саклау кагыйдәләре арасында алтын урталыкны табасы бар.

Фәрит Мөхәммәтшин мөмкинлеге чикле балалар өчен сәламәтләндерү лагерьларында инклюзив тәрбия бирү һәм укыту оештыру турында да сөйләде. Парламент җитәкчесе сүзләренә караганда, федераль дәрәҗәдә дә, төбәк дәрәҗәсендә дә бу мәсьәләгә игътибар артырга тиеш. Фәрит Мөхәммәтшин, Президиум һәм Федераль Хөкүмәт әгъзаларына мөрәҗәгать итеп, мондый балаларга ярдәм итү өчен, төбәкләрнең финанс мөмкинлеген арттыру тәкъдимен җиткерде. Әлеге тәкъдим хупланды.

Санкт-Петербургта Фәрит Мөхәммәтшин Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары буенча комиссиясе утырышын уздырды. «Бүген без яңа шартларда яшибез, күп кенә элемтәләр туктатылган, күп кенә базарлар ябылган. Ил үз икътисадын үстерүнең яңа моделен эзли. Татарстан шулай ук яңа хезмәттәшләр табарга тели, санкцияләрнең икътисадка басымын киметә. Алдыбызда импортны алыштыру, яңа базарлар табу бурычлары тора», – диде республика парламенты җитәкчесе.

Россия Закон чыгаручылар советының Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко һәм Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин уздырган утырышында да бүгенге вазгыять турында сөйләштеләр. Закон чыгаручылар советы әгъзалары белән Россия Президенты Владимир Путин да очрашты.

БУРЫЧЛЫ ХОКУКЛАР

«Хокуклар турында сөйләргә яратабыз, кайвакыт бурычларны онытабыз». Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, парламент дәресләре кысасында узган иҗади бәйгегә йомгак ясаганда, әнә шулай диде. Быелгы дәресләр «Мин – гражданин. Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән темага багышланган инде.

tatarstan.ru

Бәйгедә быел 374 укучы катнашкан. Дәүсоветта иң яхшы эссе, инша язучы, рәсем ясаучыларны бүләкләделәр. Лаеш районындагы Нармонка мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы Розалия Вафина укучылары дүртенче ел рәсем бәйгесендә катнаша. Бер ел да җиңмичә калмыйлар икән. «Быел өч бала катнашып, берсе республика этабына үтте. Идеяне без бирәбез. Алар үз хокукларын рәсемнәрдә чагылдыра», – диде Розалия Вафина.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламент дәресләренең 16 ел элек башлануын әйтте. «Балаларга кирәк бу. Мәктәпкә депутатлар килеп, Конституция, аның үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, укучыларга бик кызык. Үзем дә парламент дәресләре уздырдым, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Гади генә сораулар бирмиләр. Гади заманда яшәмибез. Өегездә дә илдәге хәлләр турында сөйләшәсездер. Әтиәниләрегез дә, сез дә борчыласыздыр. Без Украинада тыныч яшәүләрен телибез. Без сугышка каршы. Вакыйгага карата ике төрле фикер тумасын өчен, педагогларга бу хакта укучыларга аңлатырга кирәк».

Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникованың да фикерен белештек.

– Балалар өчен дә бик яхшы проект бу. Дәреслекләрдә төбәк парламентлары, Конституцияләр, уставлар турында мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Хәзер 9 нчы сыйныфта Президент, Федерация Советы, Дәүләт Советы вазыйфаларын өйрәнәләр. Ләкин балаларга аралашу җитми, минемчә. Укытучы гына сөйләп калмыйча, әгәр мәктәпкә депутат килеп, аңа сораулар бирү мөмкинлеге булдырылса, бик файдалы, – ди Римма Ратникова. – Мин Кукмара районының Манзарас мәктәбендә парламент дәресе уздырдым. Укучылар бик нык әзерләнгән иде. 15 яшьлек укучы торып басты да: «Татарстан Конституциясендә, Татарстан җәберләүләргә, сугышка каршы, дип әйтелгән. Украинадагы вакыйгалар турында нәрсә уйлыйсыз?» – дип сорады. Шул җәберләүгә каршы булганга башланды да инде ул, дип аңлаттым. Көтелмәгән сораулар бирәләр. Җәмгыять белеме белән кызыксынмаган балалар да әлеге дәресләрне рәхәтләнеп тыңлый, яңа белем туплый. Дәүләт ничек төзелә? Сайлауларга ни өчен йөрергә кирәк? Сорауларга бергәләп җавап табарга тырышабыз.

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова әйтүенчә, бүген һәр баланың язмышы укытучының тырышлыгы, зирәклегеннән тора. Бездә шундый 50 мең укытучы һәм тәрбияче эшли.

– 11 ел дәвамында һәр укучы мәктәптә 11 меңнән күбрәк дәрес укый. Кайсы мөһимрәк: беренчесеме, парламент дәресеме, әллә мәктәп белән саубуллашумы? Без моны әйтә алмыйбыз. Белем генә биреп калмыйча, тәрбия дә бирергә тырышабыз. Балаларның җиңүе – укытучының зур тырышлык нәтиҗәсе. Илебезне, туган җиребезне, табигатебезне яратыгыз, сез – табигать балалары, – диде Минзәлия Закирова бәйге җиңүчеләренә.

Сәрия МИФТАХОВА

Айдар ШӘЙХИН

Нәзарәт

«Диния нәзарәте» сүзенең мәгънәсе – дин идарәсе, дин эшләре министрлыгы. «Министрлык» мәгънәсендә бу сүз заманында Милләт Мәҗлесе тарафыннан оештырылган Милли идарә структурасына карата кулланылган. Сүзнең башка мәгънәсе – күзәтчелек итү, карау. Шул сүздән аның күзәтү (надзор) функциясен башкара торган дәүләт оешмасы мәгънәсе дә барлыкка килгән иде.

Соңгы вакытта күзгә чалынган чыганакларда (матбугат чаралары һәм эреле-ваклы пабликлар) бу сүзнең язылышында төрлелек күзәтелде. Бу – сәер хәл, чөнки 1998 елдан бирле Татарстан мөфтияте рәсми рәвештә татарча *нәзарәт* дип атала һәм бу термин бик тотрыклы рәвештә кулланыла иде.

Назәрат, нәзәрәт, назарәт түгел, ә бары тик *нәзарәт* вариантлары гына дөрес.

ЗИРАТ / ЗИЯРӘТ

Күптән түгел бер төбәктә җирле идарә хезмәткәрләренең җирле типография белән кечкенә генә бәхәсе булып алды. Вафат булган кешеләрне җирләү урыны татарча ничек атала: «зират»мы, «зиарат»мы, «зиярат»мы? Каберлекне *зиярат* дип әйтү дә еш ишетелә, ләкин сүзлектә *зират* сүзе генә каберлекне аңлата.

Эш шунда ки, телебездә *зират* сүзе дә, *зиярәт, зиярәт кылу* сүзләре дә бар.

Зиярәт итү яки зиярәт кылу кая да булса баруны, яки кемнең дә булса янына керүне аңлата (инглиз телендәге *to visit* яки русча *посетить* фигыльләре белән туры килә). Дини мәгънәдә *зиярәт кылу* дип зиратка, ягъни каберстанга барып, мәрхүмнәр рухына дога кылуны да атыйлар. Изге саналган урыннар, «изге»ләрнең каберлекләренә баруга карата да шул ук сүз әйтелә.

Зиярәт кылу – посетить булса, *посетители* сүзе – *зиярәтчеләр* була аламы? Кайбер оешмаларда бу сүзне кулланалар да икән. Гомуми алганда, әйе. Музей зиярәтчеләре, хастаханә зиярәтчеләре дигән сүздә хата юк. Ул иске татар телендә дә кулланылган, хәзер куллану очраклары да бар. Матур мәгънәгә ия булган сүзне кулланудан куркырга кирәк түгел.

Зират сүзе исә *зиярәт* дигән гарәп сүзеннән барлыкка килгән. Р. Әхмәтҗанов аның *зәрәт, зыярат* формалары да барлыгын искәртә. Башкорт телендә *зыярат* формасы кулланыла. Билгеле, кайвакыт Башкортстанга якын районнарда башкорт орфографиясенең дә йогынтысы күзәтелеп ала алуын. «Зират» тирәсендә бәхәс тә – шул йогынтының бер чагылышыдыр, мөгаен.

Онлайннарга бер генә җавап

Татар телендә «онлайн» сүзеннән соң исем сүз төркеменә караган сүз килсә, араларында сызыкча куелмый. Ни өчен? Бу мисалларга карагыз: *кара китап, яшел мүк, алтын көз, тутырылган каз, соңлаган яз, кичәге аш, тулы вариант.* Сызыкча куеламы? Сыйфат белән исем арасына куелмый.

Онлайн сервис төшенчәсен генә карыйк. Бар сервис. Ул – нинди сервис? Ул – онлайн сервис, ягъни интернетның реаль вакыт режимындагы өлешендә башкарыла торган сервис. Димәк, шулай ук исемне ачыклаучы сыйфат. Мисаллар: *онлайн ресурс, онлайн белем алу, онлайн тавыш бирү* һ.б.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Ниләр җитмидер күңелгә?!

Ульян якларында шифаханәдә ял итеп ятыш. Ашау-эчү әйбәт, кешеләр ягымлы, тагын ни кирәк инде! Әмма күңелгә нидер җитми. Ике атна буе бер генә татар җыры да ишетмәү читен, кайчак үземне зур тормыштан изоляцияләнгән кебек хис итәм. Дәваланучылар арасында татарлар очраштыргалый, тик алар күбрәк русча сөйләшергә тырыша, акыллырак, «грамотныйрак» күренәселәре килә, ахрысы. Мин аларга үпкәләмимм, хакым да юк. Рус мохитендә яшәүне кулай күрәләр икән, яшәсеннәр. Андыйларга кайда гомер итү мөһим түгел. Миңа исә читкә чыгып керү дөнья күреп кайту өчен генә кирәк. Җырда җырланганча, «читтә бәхет тапмам».

Ундоры шифаханәсе чит җир түгел. Иң әүвәл җирле халыктан «Ундоры» дигән сүзнең каян килеп чыгуы турында сораштым, күбесе аптырап калды. Шунан рус кардәшләремә «ликбез» үткәреп алдым. «Ундоры»ның «ун дару» дигән сүздән килеп чыкканын әйттем. Әле XVII гасыр башларында ук монда татарлар яшәгән, шушы тирәләрдә шифалы сулы ун чишмә агып торган, татарлар чишмә суын даруга тиңләгәннәр, аны төрле зәхмәтләрдән арыну өчен кулланганнар, дидем. Әлбәттә инде, Явыз Иван фәрманы белән татарларның зур елга буйларыннан куылуларын сөйләп тормадым. «Татарлар моннан киткән, ә авыл исеме «ун дару»дан «Ундоры»га үзгәртелеп яшәп калган», – дидем. Урыс кардәшләр: «Да... интересно», – диештеләр. «Кому как» инде.

Ике арада бернинди дә бәхәс купмады. Миңа бик үк сокланып булмаса да, хөрмәт белән карадылар кебек, спасибо, кәнишне.

Тик күңел барыбер бик үк тыныч түгел. Тукай әйтмешли, «миңа бар да ят монда». Ашханәдә бер өстәл янына утырып ашаган татарларыма хәтле урысча сөйләп азапланалар. Ә менә Уральск шәһәреннән ял итәргә килгән казах егете Телек (Теләк) минем белән татарча сөйләшергә азапланды.

Хөрмәт йөзеннән мин дә белгән кадәр казах сүзләрен кулланырга тырыштым. Кыскасы, бик якынайдык без аның белән. Телек миннән дүрт көнгә иртәрәк кайтып китте, китәсе көнне таң тишегеннән булмәгә саубуллашырга керде, Уральскига кунакка чакырды. Насыйп итсә, барырмын, ни дисәң дә, Уральск – газиз Тукаебыз 12 ел яшәгән, шагыйрь булып өлгергән шәһәр.

Тукай рухы калган җирләр минем генә түгел, бөтен татар өчен чит булы алмый. Шуңа күрә Уральскида күңелем бәргәләнмәс, киресенчә, рухи яктан тагын да баеп кайтырмын. Ульяндагы рус кардәшләр дә: «Еще приезжайте!» – дип калды үзе. Әмма монда тәнгә сихәт кенә алам шул.

МАЙ КЫТЛЫГЫ

pixabay.com

Моннан берникадәр вакытлар элек бу юлларның авторы «Сөт өчен тартыш» дигән язма әзерләгән икән. Әле ул чакта «пандемия кризисы» дип йөртелгән мәтәлчек башланмаган, безне санкцияләр белән дөмбәсләмиләр. Дөньякүләм базарларда илләр үз товарларын сату өчен көрәш алып бара. Безнең авыл хуҗалыгы тармагына, бигрәк тә сөт җитештерүчеләргә авырга туры килә, чөнки авылны «пальма мае» дигән зәхмәт белән «тукмыйлар». Индонезия белән Малайзия – пальма мае җитештерүче төп ике ил – арзанлы, әмма сәламәтлек өчен зыянлы ул продуктны Россиягә тонналап-тонналап тәяп озата. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы түрәләре моңа каршылык күрсәтмәкче булып карыйлар каравын. 2020 елның 11 февралендә Евразия икътисади союзына кергән илләрнең (Россия, Казахстан, Әрмән Республикасы, Белоруссия) белгечләре, җыелып, сөт урынына пальма мае кулланып җитештерелгән продуктларга каршы зәгыйфь кенә көрәш оештырып карыйлар. «Пальма мае кушылган продуктны сөт дип атамаска» дигән кагыйдә кертмәкче булалар. Әмма Роспотребнадзор, Россельхознадзор, Икътисади үсеш министрлыгы вәкилләре моңа каршы чыга, үсемлек маеннан җитештерелгән сөт продуктларының базарда күп урын алып торуына сылтап, икътисади кыенлыклар тудырачак дип, инициативаны кире кагалар. Бу юлларның авторы шул уңайдан ачыргаланып язган: «... Пальма мае җитештерүче илләр безгә аны көчләп диярлек бирәләр. Пальма мае турында берәр түрә авызыннан берәр җайсыз сүз чыктымы, дипломатик җәнҗалга тиң җәнҗал куба». «Чынлыкта, металл ватыгына алыштырмаслык продукт озаталар безгә Азиядән», – дип тә өзгәләнгән. Хагы шул: Малайзия һәм Индонезия сәясәтчеләре, пальма маен Россия базарына этеп кертү өчен, чып-чын көрәш алып баралар һәм уңышка ирешәләр: аны сатып алу елдан-ел кискен темпларда арта. Авызыңа конфет каптыңмы – пальма мае йотасың, торт сатып алдыңмы – пальма мае күтәреп кайтасың... Арзанлы пальма мае белән үзебезнең продуктлар көндәшлек итә алмый, авыл хуҗалыгы мәңгелек кризиста яшәргә мәҗбүр була, сатып алу бәяләренең түбәнлегеннән интегә.

Юк, бу юлы мин сыер савучыларны яклап язмыйм әле. Глобаль икътисадта барган сәер һәм аек акылга сыймый торган үзгәрешләр хакында сөйләшергә телим. Бу шулкадәр мөһим, чөнки безнең якындагы киләчәгебезгә зур дәһшәт яный. Эш шунда: пальма маена каршы көрәш кәтмәгәндә кискен чишелешен табып ята. Индонезия 28 апрельдән башлап пальма маен экспортлауны тыя. Имештер, күптән түгел генә кая куярга белмәгән сыйфатсыз май Азия гигантының үзенә дә җитми икән. 2021 елда Россия Индонезиядән 1 миллион тоннадан артык пальма мае сатып алып, кәнфиткә һәм сөткә-сыргә әйләндергән. Пальма маен экспортлауны Малайзия дә тыя, ул – Россиягә май сатучы икенче ил. Юк, болар безгә каршы санкцияләр кертмиләр, ә экспортны «үзебезгә җитми» дигән формула белән туктаталар. Кызык бит инде, әйеме: әле генә кая куярга белмиләр иде, хәзер – кытлык. Россия складларында берничә айга җитәрлек май запасы бар дип уйлыйк. Ә аннан соң? Җитмәсә үткән көздә, фуражлык ашлык кыйммәт дип, күпләр сыерларны да бугазладылар. Бәлки, берничә айдан соң Индонезия тышкы базарларга үзенең сыйфатсыз маен тагын этеп-төртеп кертергә азаплана башлар һәм без яңадан арзанлы кәнфит ашауны дәвам иттерербез. Башламаса, кызыклы вазгыять туа. Нәтиҗәләрне әлегә кузаллау да кыен.

Планетага азык-төлек кризисы һәм глобаль ачлык янавы турында белгечләр күптән шау-шу кубаралар инде. Махсус хәрби операция башлагач, ашлык һәм үсемлек майлары экспортлаучы төп ике ил – Россия белән Украина, танкларга утырып, мөнәсәбәтләрне ачыклау сәбәпле, ачлык куркынычы инде бусагага килеп җитте, дип расларга да ярата башладылар. Белоруссия ашламалары сатылмау да ачлыкка үзеннән өлеш кертер дип әйтәләр. Берникадәр манипуляция дә бар ул раслауларда. Кайчандыр бу өч илне үзенә берләштергән СССР ашлыкны да, башка азык-төлекне дә читкә сатмый, күпләп сатып ала, әмма ачлык юк иде. Хәзер ни өчен андый куркыныч туа? Кытлыкка ни сәбәп бар? Бу сорауларга җавап табу – бик мөшкел эш. Бу юлларны язучы үзенең субъектив фикерен генә китерә ала: ачлыкны махсус оештырырга тырышалар. Нидидер көчләргә планетада зур хаос һәм шок кирәк. Бәхәсләшә аласыз, әмма без үзебезнең башка дәлилләрне китерәбез.

Энергетик кризис та махсус оештырыла. 2020 елның 3 сентябрендә «Ватаным Татарстан» сайтына «Ай, «Газпром», вай, «Газпром»...» дигән язма элгәнбез. Аның кереш өлешендә: «Кайчандыр Европа илләренә шартлар куйган, бик үк дус булмаган аерым илләрне икеләтә тунаган «Газпром» газ сата алмый, сатса, түбән бәядән генә. «Газ коралы» дигән сүз якындагы тарих чүплегендә күмелеп калды», – дип язганбыз. Төрек радиосы ул чакта: «Беренче яртыеллыкта «Газпром» табышы 25 тапкыр кимеде», – дип шаулаган. АКШ Кытайга үз нефтен һәм газын сату өчен «сәүдә сугышы» игълан иткән вакытлар бу. Газга бәя шулкадәр түбәнәя: үзкыйммәтне каплый алмый. Хәзер дөнья базарындагы «зәңгәр ягулык» бәясенә карагыз. 2020 ел белән чагыштырганда, җиде-сигез, хәтта ун тапкыр артты. Бер нәрсәне ассызыклыйк: энергетик кризис махсус хәрби операциягә кадәр үк башланды. Европа илләре үткән көздән үк җылылыкка бәяләрдән интегәләр инде. Димәк, бер ел эчендә куярга урын табып булмаган «зәңгәр ягулык» никтер дефицитка әйләнгән. Сорау куябыз: газ кая китте? Җавабыгыз бармы? Менә шул-шул.

Әйдәгез, нефтькә карыйбыз. 2020 елның 20 апрелендә сайтка «Нигә чирләден, «кара алтын?!» дигән язма элгәнбез. Керештә мондый сүзләр: «Сишәмбе көнне Американың нефть базарында көлсәң көл, еласаң ела дип әйтерлек хәлләр булды. Эталон WTI сортлы Америка нефтенең бәясе минуска китте». Чып-чын минус турында бара сүз. Нефть эшкәртүче шундый компанияләр булды: нефтьчеләргә акча түләсәгез генә алабыз нефтегезне, дип ялындылар. Россия Кытайга «кара алтын»ны үзкыйммәтеннән түбәнгә озатып ятты. Озак бармады ул хәл, әмма... Шул елның мартында без: «Согуд Гарәбстаны Мәскәү өстендә «кара алтын» җиһады кылычын болгый: айлар буена рекордлы күләмдә нефть белән базарларны коендырып торырга вәгъдә итә», – дип тә язганбыз.

Америкада «Уолл-стрит джорнэл» (WSJ) дигән көндәлек газета чыга. Бик йогынтылы һәм зур тиражлы газета. Менә шул WSJ соңгы көннәрдә яза: «Вашингтон Эр-Рияттан, дөнья базарындагы бәяләрне төшерү өчен, нефть чыгаруны арттыруны сорады, әмма кире җавап алды», – ди. Моннан нәкъ ике ел элек Россиягә каршы нефть җиһады игълан итеп, бәяләрне чүпкә калдырган ил, ни өчен кәтмәгәндә Мәскәүнең аркадашына әверелде? Кызык сорау бит, әйеме? Андый сораулар, дәвам итсәң, бик күп әле.

Россиянең Куркынычсызлык советы секретаре Патрушев яңа гына «РИА Новости»га: «Трагические сценарии мировых кризисов как в прошлые годы, так и сегодня навязываются Вашингтоном в его стремлении закрепить свою гегемонию», – дип белдерде. «Россиянең суверенитетына куркыныч яный», – дип тә әйтәсе килә аның. «Вашингтон гегемонлыгы» дигәне бик үк барып чыкмый әле никтер, америкалыларның аяк астыннан җир шуыша. Киресенчә, алар үзләре дә нииндидер бер башка көчнең басымы астында хәрәкәт итәләр кебек тоела. Бу юлларның авторы дөнья дәүләтләренең берсе дә абсолют суверенитетка ия түгел, лидерлар барысы да кушканны үтәү белән шөгыльләнә дип саный. Шулай булмаса, Украина мәйданында гаҗәп хәлләр барыр идемени? Техник максатларга гына яраклы пальма маена кытлык (ясалма кытлык дип әйтик) туар идемени? «Бөтендөнья хаосын кем оештыра?» дигән сорауны без ачык калдырабыз. Зур һәм бөек шок алдында торабыз, монысы белән бәхәсләшмәссездер дип уйлыйм.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЫЙГАК-КЫЙГАК, БАК-БАК-БАК

«ЙОРТ КАЗЫ АКЫЛЛЫРАК ТА, ТӘМЛЕРӘК ТӘ», – ДИ КОШЧЫЛАР

Элек авылларда каз бәбкәләрен бастырып чыгару кебек күркәм бер гадәт бар иде. Соңгы елларда авылларда йорт казлары асраучыларны чыра яндырып эзләсәң дә таба торган түгел, булса да, бик аз андыйлар. Нурлат районы Кизләү авылында яшәүче Таңсылу һәм Мәүлет Рәхимовлар исә менә инде егерме еллар тирәсе бәбкәләрне бастырып чыгарта. Әлеге гаилә белән онытыла төшкән матур күренеш турында сөйләштек.

Рәхимовлар әйтүенчә, казлар, гадәттә, йомырканы март урталарында сала башлый. Утырган вакыттаояга арыш саламы салу яхшы икән.

– Каз төнлә ашарга ярата. Кичен, кояш баегач, бер-берсе белән «сөйләшеп» туя алмыйлар. Йомырка яхшы салсын дисәгез, кышын ашату белән сак булырга кирәк. Азыкның артыгын бирү яхшы түгел. Симергән кошның йомыркасында майлылык күп була да, яралгыга зыян килә. Ә йомырканың бушмы-юкмы икәнлеген ун көннән соң карап белергә мөмкин. Күп очракта бәбиле була, – ди гаилә башлыгы.

Бәбкәләр чыгу мәсьәләсендә исә ел елга карап килми икән. Өченче ел ике каз унсигез бәбкә чыгарып, хуҗаларны сөендерсә, узган ел 4 кенә бәбкәле булганнар. Әнкәләре аларның да берсен генә үстерә алган.

– Кошларны сатып алып өстәгәнебез юк. Шулай да бер елны чыкмагач, инкубаторныкын алып кушкан идек, ияртеп киттеләр үзләре тагын, – ди хуҗабикә.

Әңгәмәдәшләрем әйтүенчә, бер каз астына йомырканы казның гәүдәсенә карап куялар.

– Әгәр күкрәге киңрәк икән, унбишне куярга була. Ояда утырганда казлар бер-берсеннән аерыла. Беришләре бик чиста-пөхтә була, икенчеләре ояларын тузгытып бетерә. Алар кеше кебек: уңганы һәм ялкавы бар, – ди Мәүлет абый.

Аның әйтүенчә, бәбкә чыгарып алдыннан казлар усаллана башлый. Ә инде кечкенәләр күзгә күренгәч, бөтенләй янарына якын килерлек булмый.

– Моңа кадәрге әнкә казыбыз бәбкәләрне июнь урталарында гына чыгара иде. Ата казларны 3–4 ел саен алыштырып торырга кирәк. Кайвакыт алыштырырга каз эзләп йөрибез, таба алмыйбыз. Чөнки асраучылар юк. Нәсел югалса, бик начар инде. Моңа кадәрге ана казыбыз бик акыллы иде безнең. Узган ел аксагач, ана казларны яңарттык. Ата казны да алыштырган идек, кызык булганбыз әле: өчесе дә ана каз булып чыкты. Йомыркалар буш булыр инде, дип йомырка алып кайттык. Каз астына аларны да куярбыз, дибез, – ди ул.

Сөйләшә башлаганда ук Таңсылу апа: «Бөтен рәтен, төмен Мәүлет абыегыз белә, мин – ияреп кенә йөрүче», – дип кисәткән иде. Чыннан да, гаилә башлыгы кошлар турында шулкадәр яратып, тәмләп сөйләде.

– Иң беренче елда казны шактый өлкән яшьтәге бабайдан алган идем. Нәселле йорт казлары иде алар. Шул чагында ул: «Йорт казын асрап кара әле син. Аннан соң тәме турында сөйләшербез», – диде. Чыннан да, алар тәмнәре белән бик нык аерыла. Бөтен мае итендә аның. Дөрес, йорт казының гәүдәсе җиңелрәк, ләкин итенең тәме гел үзгә инде. Караввы да җиңел. Йорт казы – холкы буенча бик кызык кош. Ул акыллырак. Юлларын бик тиз истә калдыралар. Суга бер тапкыр төшерү җитә аңа. Ә инкубаторныкылар кая барганын үзләре дә аңламый. Аларның холкы суда йөзгәндә бигрәк тә нык аерыла. Йорт казы тавышлы, хәрәкәтчән. Инкубатордан чыккан бәбкәләргә, ияртеп йөртер өчен, командир кирәк. Йорт казының ишегалдында тавыш биреп куюлары да өйгә ямь бирә инде. Алар бәбкәләрен дә карга-чәүкәгә бирмичә, үзләре карап-саклап үстерә. Ашарга, суда йөзәргә, тәртипкә өйрәтә. Башкалар инде: «Алар белән җәфаланганчы, сатып алам», – ди. Ә мин шуларны караудан рәхәтлек алам, – ди гаилә башлыгы.

Моннан тыш, Мәүлет абый әйтүенчә, ата каз бик сайлаучан була икән.

– Ул ике ана каз арасыннан берсен генә ярата. Шуңа күрә иртән ата казны чыгармыйча торып, яраткан ана казны аерып алып, икенчесен калдырабыз. Мәхәббәтләре дә кешеләрнеке төсле. Ир белән хатын кебек ачуланышалар, оя бүлешәләр, хәтта йомыркаларга кадәр урлашалар. Аларда да нәфес дигән нәрсә бар, – ди ул.

Казлары гына түгел, тавыклары да тырыш икән Рәхимовларның. Быел инде җиде чебеш чыгарырга өлгергән. Менә шулай тормыштан тәм табып, булганына шөкер итеп, эшләгән эшләреннән ләззәт алып яши гаилә.

«Чеби үстергәндә иң мөһиме – чисталык»

Питрәч районының Шихазда авылында яшәп, чебиләр алып кайтып сатучы, бройлер, күркәләр үстерүче Зөлфия ШӘЙХЕЛИСЛАМОВА белән кош-кортларны тәрбияләү үзенчәлекләре турында сөйләштек.

pixabay.com

:: Зөлфия апа, чеби һәм каз бәбкәләре алып үстергән кешеләргә нәрсәне истә тотарга кирәк?

– Беренчедән, ветеринар-санитар чараларны үтәргә кирәк. Чебешләрнең торган җирләре чиста, дезинфекцияләнгән булырга тиеш. Аларны агач сарайларда үстерү үткәндә калырга тиеш инде. Чөнки ул – микроблар өчен бик уңышлы җирлек. Агачны бетон яки сэндвич панель белән алыштырырга кирәклеген күптәннән сөйлим. Моннан тыш, кош-корт торган урында һава яхшы йөрергә тиеш. Бина эче җылы булсын. Бройлер чебиләрен, мәсәлән, артык иркен урында тотмаска киңәш итәм. Ул бер квадрат метрда 13 сәгать утырырга тиеш. Ашапэчәргә, бераз селкенергә урын булса, аңа шул җиткән.

:: Туклану буенча нәрсә киңәш итәр идегез?

– Комбиазыктан «Богданович» дигәне иң яхшылардан санала. Зуррак чебиләргә дә башта комбиазык, аннан соң акрынлап үз ризыкларын бирү яхшы. Алып кайту белән үк ни бар, шуны бирү дөрес түгел. Профилактика максатыннан өч көн антибиотиклар эчерү яхшы. Эчәклек микрофлорасын яхшырту өчен, берничә көн пробиотик бирергә онытмасыннар иде. Һәр үсеш чорының үз рационы бар. Бер тәүлеклек чебиләргә – бер төрле, зурракларына башканы бирергә кирәк. Моннан тыш, кош-корт алдында һәрвакыт азык белән су торырга тиеш. Һәм савытларның биеклеге муен белән бер дәрәҗәдә булуы кирәк. Кешеләр кошларның су һәм азык савытын һәрвакыт чистартып торсалар иде. Тизәк, тирес, агач чүбе төшкән савыттан ашаган чебине озын гомерле һәм сәламәт булыр дип әйтеп булмый.

:: Бөтен кешенең дә кош-кортларны каядыр барып алырга мөмкинлеге юк. Шуңа күрә халыкның күпчелеге чебиләрне, каз бәбкәләрен авылга китереп, машинадан сатып йөрүчеләрдән ала. Мондый вакытта алар нәрсәгә игътибар итәргә тиеш?

– Әгәр мөмкинлек булса, бер генә кешедән сатып алырга тырышырга кирәк. Беренчедән, бу ышанычлы, икенчедән, микрофлора өчен дә яхшы. Шулай ук чебиләрне алып килгән машинаның эче дә чиста булуы бик мөһим. Үз-үзен хөрмәт иткән кошчы машинаны гел чиста-пөхтә, тәртиптә тота, кошлар торган тартмаларны юа. Болардан тыш, чебешләрнең каурый, йоннары тырпайган булмаска, күзләре тонык, күз агы кызыл түгел, ә ачык, түгәрәк (озынча күзле кош авыру була), чеби үзе тере, хәрәкәтчән булырга тиеш. Тәүлеклек чебине аркасына яткырып тикшереп карарга киңәш итәм. Тиз генә аягына баса икән, яхшы. Ә инде егылгач, озак тора алмый ятса, андый бәбкә өметле түгел. Тагын бер төрле сынап карарга мөмкин: бәбкәне аркасына яткырып, кендеген карагыз. Әгәр ул эчкә суырылган һәм караңгы төстә яки төзәлеп бетмәгән икән, авыру булырга мөмкин. Шулай ук кендек шар сыман кабарган да булмаска тиеш. Өйгә алып кайткач, чебигә суга 40 г глюкоза һәм 2 г аскорбинка болгатып эчертү бик әйбәт. Алай эшләү җае булмаса, шикәрле су яки 200 мл сөтне 3 литр суга кушып эчертергә яки витаминнар комплексы бирергә кирәк. Бройлер күбрәк тәрбия таләп итә.

:: Халык арасында каз бәбкәләренең кайсы токымнары аеруча популяр?

– Халык казларның Линда, Холмогор токымлыларын сайлый. Узган ел белән чагыштырганда, быел кош-корт бәясе 20–40 процентка артты. Әллә шул сәбәпле быел сорау һәк кимеде. Фермерлар да инкубаторда азрак чыгара. Ләкин минем электән килгән даими клиентларым бар. Ләкин үз сатып алучыларым арасында да бройлерга ихтыяҗ сүлпәнәйде.

МАШИНА БЕЛӘН ЙӨРЕП САТУЧЫДАН КОШ-КОРТ АЛГАНДА ИСТӘ ТОТАРГА КИРӘКЛЕ КИҢӘШЛӘР

▶ Иң беренчесе һәм мөһиме: авылларга кош-корт китереп сатучылардан ветеринария белешмәләрен сорау. Бер дә булмаганда, машина номерын язып алырга яки фотога төшереп калырга кирәк. Кош сатучыларда мондый документ һичшиксез булырга тиеш. Күрсәтүдән баш тарталар икән, димәк, законга каршы килеп эшлиләр.

▶ Кош-кортларның базардагы уртача бәяләрдән арзанрак булуы шулай ук шик уятырга тиеш. Белгечләр әйтүенчә, карантин кертелгән төбәкләрдә кош бәяләре уртача базар бәясеннән күпкә арзанрак була. Мондый арадашчыларның кулларында ветеринария документы булу мәҗбүри.

▶ Авыл җирлеге башлыкларына да игътибарлы булырга кирәк. Алар авылларга кош-корт сатучыларны махсус рөхсәт кәгазеннән башка кертергә тиеш түгел. Болардан кала, районнарда кош-корт сата торган махсус мәйданчыклар эшли.

Бәяләр

- ✓ Бер тәүлеклек бройлер – 110 сум
- ✓ Бер тәүлеклек күркә – 470 сум
- ✓ Бер тәүлеклек каз бәбкәсе – 280 сум
- ✓ 35 көнлек бройлер – 355 сум
- ✓ 19 көнлек үрдәк – 230 сум
- ✓ 20 көнлек Мулард токымлы үрдәк – 420 сум
- ✓ 35 көнлек күркә – 1500 сум

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

УКЫГАН САЕН УКЫЙСЫ КИЛӘ

НАЧАР ХӘБӘРЛӘРГӘ БӘЙЛЕЛЕК НӘРСӘСЕ БЕЛӘН КУРКЫНЫЧ?

Күңелле хәбәрләр тансык заманда яшибез. Бер карасаң, кеше начар яңалыклардан арыну җаен карар иде. Арабызда исә аларны махсус рәвештә эзләп, табып, йотлыгып һәм теләп укучы-караучы-тыңлаучылар да бар икән. Соңгы берничә елда андыйлар саны арта бара, ди белгечләр. Бу күренеш «думскроллинг» дип атала. Аның психикага тәэсире нинди? Тискәре яңалыклар агымына каршы торып буламы?



pixabay.com

Нәрсәдән гыйбарәт?

Соңгы елларда кешелекнең сабырлыгы шактый сыналды. Әле чир, әле изоляция, хәзер инде башка бәла-казалар шаукымы тәэсирендә яшәргә туры килә.

«Думскроллинг» термины да коронавирус пандемиясе котырган чорда барлыкка килгән иде. Ул, гади итеп әйткәндә, тискәре хис-кичерешләр уятуга карамастан, начар яңалыклар белән танышырга омтылу дигәнне аңлата. Сүз уңаеннан: 2020 елның мартында коронавирус турында шомландыргыч яңалыклар уку эзләү системаларында иң популяр гамәлләрнең берсе булган. Хәзер исә тискәре хәбәрләргә бәйле кешеләрнең саны 30 процентка арткан.

Әлбәттә, думскроллинг пандемия темасы белән генә чикләнми. Ул көн кадагында торган актуаль хәлләргә бәйле рәвештә үзгәреп тора. Контрольдән чыккан думскроллингның төп сәбәбе – мөһим яңалыкларны күз уңыннан ычкындырам дип курку. Кызыксынучан баш мие гел нәрсәдер аңларга, белергә омтыла, шәхеснең үзенә тегe яисә бу күренеш ничек кагыласын төшенергә тели.

«ВТ» хәбәрчесен думскроллинг күренешенә аерым тукталырга Булат исемле әңгәмәдәше этәрде. Ул да үзен думскроллер дип атый ала икән инде. Ник дигәндә, иртәсе куркыныч, начар хәбәрләрне махсус эзләүдән, укудан башланып, киче дә шулай тәмамлана. Социаль челтәрләрдә күбрәк шундый хәлләрне яктырткан төркемнәргә язылган. «Бөтен кешелекниндидер хәбәрне укыр да, аны мин белми калырмын кебек тоела. Ә дөнья арбасыннан төшеп каласы килми», – ди ул.

«Дөнья арбасында күңелле яңалыклар да бар бит», – димен Булатка.

– Билгеле, бар. Әмма начар хәбәрләр кешедә күбрәк хис-кичерешләр уята, адреналин өсти, ярсыта бит, – дип җавап бирде ул. – Мин контрольсез рәвештә ил-көндәге вазгыятькә, хәрби, сәяси тематикага кагылышлы яңалыкларны укырга яратам. Ә бу кырда күңелле яңалыклар юк диярлек. Башка сыймаслык куркыныч вакыйгалар да гел булып тора. Алары инде шаккатыра, «кеше ничек шулай булдыра ала соң» дигән уйга этәрә. Үзем генә укымыйм: башкаларга да шундый ук яңалыкларны җибәрәм. Бу гадәтне үзгәртә дә алмыйм шикелле инде.

Белгечләр ни уйлый?

Бик нык теләсәк тә, дөньядагы барлык яңалыклардан хәбәрдар булу мөмкин түгел. Тиз үзгәрүчән хәзерге заманда бигрәк тә. Шуңа күрә көн кадагындагы мәсьәләләрне «йоту» белән мавыгырга кирәкми, дип кисәтә белгечләр. Юкса сәламәтлек дигән бик кадерле нәрсәбез какшый башламагае.

Клиник психолог, фән кандидаты, психотерапевт, бәйлелек белән көрәш үзәге җитәкчесе Денис Макаровский думскроллингны кеше организмының стресска каршы реакциясе дип аңлата. Шуңа күрә, аннан котылу өчен, иң элек стресс чыганагын бетерергә кирәк.

Сан

«Зарплата.ру» тикшеренү порталы уздырган сораштыру нәтиҗәсенә караганда, думскроллинг хезмәт урынындагы кешенең игътибарын читкә юнәлтә торган күренешләр арасында икенче урынны били. Бер максатсыз тискәре яңалыклар тасмасын карап утыру турында сораштыруда катнашучыларның 15 проценты белдергән. Беренчелектә исә социаль челтәрләрдәге шәхси чатларда аралашу тора.

– Безнең баш миебез мәгълүмат һәм калория кытлыгыннан формалашкан. Бу эволюция дәрәҗәсендә шулай. Шуңа да кайчагында аларны бертуктаусыз кабул итүдән туктый алмыйбыз да бит инде, килешерсез, – дип аңлата белгеч. – Үзеңне моны эшләмәскә мәҗбүр итәргә кирәк. Башка юл юк. Теләсә кайсы мәгълүматны кабул итүнең максаты бар. Шуларның иң мәгънәсезе – сиңа берничек тә йогынты ясамый торганын уку-карау-тыңлау. «Мин нәрсә телим?» дигән сорауны ешрак бирергә кирәк, шул исәптән яңалыклар тасмасын сыпырганда да. Бар нәрсәдән дә хәбәрдар булу кирәк түгел. Үзегезгә кирәген генә белү дә җиткән.

Кеше табигый ихтыяҗы аркасында думскроллинг белән шөгыльләнә. **Психолог Галия Гыймадиева** шундый фикердә. Борынгы заманнарда ук кешеләр, исән калу өчен, куркыныч тудыра торган вакыйгалардан шүрләргә күнеккән. Думскроллинг очрагында да, мәгълүматны алдан укып, без үзебезне мөмкин булган күңелсезлекләргә алдан әзерлибез кебек килеп чыга.

– Баш мие шулай көйләнгән: физик һәм хисси яктан безнең барысы да яхшы булырга тиеш. Шуңа күрә иң элек баш мие тискәре мәгълүматны иләк аша чыгара. Бу табигый, – ди белгеч. – Бер караганда, моның бернинди куркынычы да юк кебек. Әмма кешеләр, дөрестән дә, моңа ияләшә, бәйлелек башлана. Әмма без – аңлы затлар бит. Фикерләвебез белән идарә итә алабыз, дөрес юнәлешкә борырга сәләтлебез. Начар яңалыклар эзләү белән мавыгасыз икән, үзегезгә «Бу миңа ни өчен кирәк?» дигән сорауны бирегез. Мондый яңалык укыганнан соң сез нәрсә эшләячәксез, нинди гамәл кылачаксыз? Юкка гына булырга тиеш түгел. Тискәре мәгълүмат уку-карау-тыңлау да аңлы рәвештә башкарылырга тиеш. Кире очракта организмны борчылу, хафалану көтә. Үзебез үк үзебезне шушы юлга кертәбез. Ә хафалы кешеләр негатив яңалыкларны эзләүгә тагын да күбрәк дучар.

Галия Гыймадиева әйтүенчә, тискәре фикерләү гадәтегез бар һәм аның сезгә тормышта кыенлык тудыруын сизәсез икән, димәк, үзегезне кайгыртыр вакыт җиткән. «Тормыш мәшәкать һәм авырлыклардан гына тормый. Иң кыен вазгыятьтә дә, иң авыр чорда да яхшылык очкынын табарга мөмкин. Тышкы тирәлектә барысы да җимерелгән чакта да, эчке терәүләр нык булсын. Ә бу терәүләр төрле кеше өчен төрле: кемгәдер ышанычын арттыру, кем өчендер Аллаһы Тәгалә белән элемтә, кайсылары өчен эчке принциплары. Үзеңне өйрәнергә һәм белергә кирәк, бу төшенкелек чорында үзеңә ярдәм итәргә булыша», – дип сөйләде психолог.

Белеп тор!

АРТЫК КҮП МӘГЪЛҮМАТ АЛУ: СӘБӘП ҺӘМ БИЛГЕЛӘРЕ

➤Кеше күп төрле тармакларда белгеч булырга омтыла. Гадәттә, ул өлкәләр бер-берсеннән шактый аерыла һәм төрле була.

➤Кеше мәгълүматтан ял итә белми. Ял иткәндә дә үзен мәгълүмат кырында – киеренкелектә калдыра: социаль челтәрләр тасмасын актара, яңалыклар укый, яңа мәгълүмат эзли. Экранга бармак белән төртүдән ләззәт ала.

➤Кеше эш процессын оештыра һәм эш белән шәхси тормышны аера белми.

➤Болар барысы да иртәме-соңмы алган мәгълүматны оныту, кирәген хәтердә саклый алмауга китерәчәк. Мәгълүматның артык күплеге тегe яисә бу очракта тиз арада кирәкле карарга килергә комачау итәчәк.

➤Игътибар кими, бу инде эшне җиренә җиткереп башкару һәм аның сыйфатына йогынты ясый.

➤Төшенкелек, билгесезлек, өметсезлек хисләре баш калкыта башлый. Курку, киеренкелек көндәлек юлдашка әйләнә.

Укымаска түгел укырга

Өтерне дөрес урынга куярга ничек өйрәнәсе соң? Белгечләр моның авыр, әмма мөмкин эш булуын искәртә. Ихтыяр көчен туплаурга гына кирәк.

Беренчедән, гаджетларны белеп кулланырга өйрәнегез. Бигрәк тә төнлә – йокларга ятар алдыннан. Төнгә каршы чир, сугыш, гадәттән тыш хәлләр хакында яңалыклар карамаска, укымаска киңәш ителә. Мөстәкыйль рәвештә телефонны читкә алып куярга көчегез җитми икән, берәр кешегә әйтеп, моның турында искә төшереп торуын сорагыз. Йә инде телефонга махсус таймер йөкләгез. Гомумән, телефон сыпыруга дигән вакытыгызны чикләсәгез, тагын да хәерлерәк. Галимнәр бер кызык ысул да тәкъдим итә. Телефонның төсләр гаммасын (цветовая гамма) актан сорыга күчереп карагыз әле. Күзләр, аклыкка ияләшеп, сорылыкка бик ашкынмас. Шул рәвешле телефон да кулда азрак тотылыр иде. Гомумән, кайбер психологлар яңалыклар белән танышып чыгу өчен тәүлекнең 15 минуты да җитә дип саный. Йә булмаса иртән һәм кич яртышар сәгать вакытны шуңа багышларга өнди.

Икенчедән, дөрестән дә файдалы мәгълүмат бирерлек яңалыклар белән генә танышыгыз. Социаль челтәрләргә максатчан керегез һәм нәрсә өчен керүегезне истән чыгармагыз. Бәлки, сез коймак пешерү рецептын эзлисездер? Димәк, фәлән урында фәлән кешене чәнчүләре турында белү сезгә кирәк түгел бит!

Өченчедән, ничек кенә гади яңгырамасын, яңалыклардан ял итеп тору кирәк. Тормыш бит туры эфир, газетадагы репортаж, радиодагы тапшыру һәм интернет челтәрендәге яңалыклар тасмасы белән генә чикләнми.

Дүртенчедән, телефон сыпырып утырудан тыш шөгыль табыгыз. Китап уку, яңа фильм карау, дус-ишләр белән очрашу, актив ял, мәсәлән. Болар хәзер күпкә әһәмиятлерәк һәм кеше өчен кирәгрәк тә. Күңел ачуга корылган мәгълүматны уку-карау-тыңлаудан да оялмагыз (чамасын белеп, әлбәттә!). Тискәре уйларга бирелгәнче, елмаеп алу күпкә хәерлерәк бит. Көлү гомерне дә озайта, диләр.

6 майда сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә ГЫЙЛАҖИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Сәбәбе нидә?

Әнием исән чакта, без бакча өчен дә, каралты-курага да салым түләмәдек. Ул үлгәч, миңа ел саен салым түләргә туры килә. 80 яшьтә инде мин дә. Бакчам өчен – 947, пай җире өчен 430 сум түлим. Нигә миннән салым түләтәләр икән?

Разыя БӘХТЕГӘРӘЕВА.
Тукай районы Яңа Байлар авылы

Тукай районы Күзкәй авылы җирлеге башлыгы Эдуард Гәрәев:
– Бездә өлкән яшьтәге кешеләр милек салымыннан азат ителде. Пай җирләре өчен I, II группа инвалидлар, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучылар салым түләми. Калган кешеләр бакчасы өчен дә, пай җире өчен дә салым түли.

Ничек күчертим?

Кызым шәһәрдә яши. Авылдагы йорт – минем исемдә. Күрше әби, ире үлгәч, өен үз исеменә 11 мең сум түләп күчерткән. Мин үлгәч, кызым шулай күп акча түләмәсен өчен, йортны ничек итеп аңа күчереп була икән?

Гөлфия СӘЕТГӘРӘЕВА.
Казан

Юрист Рәзил Билданов:
– Йортны якын кешеңә калдыруның ике юлы бар. Беренчесе – бүләк итү. Әмма ул йорт бүләк ителгән кешенең кереме булып исәпләнә ала. Ул салым инспекциясе аша уза. Салым түләргә туры килүе бар. Йорт бәясенең 13 процентын түлисе була. Икенче юлы – васыятьнамә ясату. Бу очракта нотариуста дәүләт пошлинасы түләргә туры киләчәк.

Улыма фатир эләгерме?

Кияүгә чыккач, миңа балам белән авылга кайтып китәргә туры килде. Ирем исә гаиләбезгә фатир өчен биреләсе акчаны көтеп калды. Аңа акча түгел, фатир биргәннәр. Мин ул чакта, аягымны авырттырып, хастаханәгә эләктем, ирем исә, фатирны алуга, фаҗигагә юлыккан. Йөри алмау сәбәпле, аны соңгы юлга озата алмадым. Баксаң, 6 ай эчендә миңа барлыгымны белдерергә, фатирыбызга барырга кирәк булган. Мин аны белмәдем. Җитәкчеләр ирем алган фатирга башка хатынны кертеп куйганнар. Хәзер ул авыр хәлдә. Ул үлсә, улым аның фатирына дәгъва кыла аламы?

Мөнирә СИБГАТУЛЛИНА.
Чаллы

Юрист Рәзил Билданов:
– Бик четерекле сорау. Бу фатирны иregезгә биргәннән соң күпме вакыт узды икән? Шунысын ачыкларга кирәк. Барлык документларны карау мөһим. Килешүдә ничек язылган булган? Ирегезнең бу фатирга хокукы булганмы? Ул аңа вакытлыча гына бирелгәнме, әллә бөтенләйгәме? Ирегез үлгәч, сезгә нотариустан хәбәр бирергә тиешләр иде. Әгәр алты айдан соң да фатирга дәгъва кылучы күренмәсә, тагын вакыт бирелергә тиеш иде. Сезгә дигән фатирга кергән кешеләрнең ни сәбәпле хуҗа булуларын сорарга кирәк. Улыгызга барлык документларны барлап, фатир хакында белешеп карарга киңәш итәм.

Акчамны кайчан бирерләр?

Мин эшемнән гыйнварда киттем. Шуннан соң пенсия артырга тиеш иде. Үзем яшәгән районның Пенсия фондына бардым. Алар минем белән сөйләшергә дә теләми. Бик дорфа җавап бирәләр. Көтәргә кушалар. Кайчанга кадәр көтәсе икән соң аны?

Фәрит ХИСМӘТУЛЛИН.
Казан, Совет районы

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәсе матбугат хезмәте җитәкчесе Альбина Никандрова:
– Эштән киткән пенсионерның пенсиясе индексацияләнә. Яңадан исәпләнгән акча эштән киткәннән соң өч ай узгач, дүртенче айда бирелә. Бу вакыт аралыгында Пенсия фондына әлеге кешенең эшләгән вакытындагы барлык белешмәләре килә. Шуңа да пенсиянең артуын сабыр гына көтәргә туры килә. Шунысы бар: өч айдан соң ул акчаны җыеп бирәләр. Фәрит Хисмәтуллин очрагында ул арткан пенсиясен май аенда алачак.

Укучы сүзе

13 БАЛА ӘНИСЕ АЛЬБИНА ХӘЙДӘРШИНА: «УЛ-КЫЗЛАРЫМНЫ ҮЗЕБЕЗ ӨЧЕН ТАПТЫМ»

Без гаиләдә 12 бала үстек. Алты малай, алты кыз идек. Үсеп буйга җиткәч кенә, өч абыебыз арабыздан китеп барды. Урыннары оҗмахта булсын. Аларны гел сагынып искә алабыз.

Гөлгенә ГАБДРАХМАНОВА

***

Сөбханалла! Балаларыгыз игелекле булсын. Сәламәтлек һәм озын гомер барыгызга да.

Разил ХӘСӘНОВ

***

Исән-сау үстерергә язсын. Миһербанлы балалар булып үссеннәр.

Зөлфия ГАЛӘВЕТДИНОВА

Алиментны түләтеп буламы?

Кызым ире белән аерылышты. Ике ел узса да, никтер ирен алиментка бирергә уйламады. Хәзер менә бирмәкче була, әмма ничек эш башлыйсын белми. Каенанасы, акча урынына кием-салым, ризыкларны үзебез бирербез, дип тә әйтә икән. Болай эшләргә ярыймы? Суд приставлары онлайн кабул итә дип тә ишеткән идем.

МӘРШИДӘ.
Казан

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе сорау алуны оештыру бүлеге башлыгы Рамил Шиһапов:
– Алимент түләттерер өчен, иң элек суд приставлары хезмәтенә башкару документын китереп тапшырасың. Бу суд боерыгы да булырга мөмкин, башкару кәгазе дә, нотариаль расланган килешү дә була ала. Суд приставы-башкаручысы башкару эшен кузгатып җибәрә, кабул ителгән карар турында якларга хәбәр итә һәм шуннан соң түләттерү өчен чаралар күрә башлый. Алга таба бурычлы затка карата пристав тарафыннан нинди чаралар күрелачәге башкару документын җиткерү вакытына бурычның булуына яисә булмавына бәйле. Әгәр бурыч юк икән, пристав хәзерге вакытта түләнергә тиешле айлык акчаны түләттерү чараларын күрә. Әгәр бурыч бар икән, ул очракта хәзер түләнергә тиешле акчага бурыч күләме дә өстәлә, анысы аерым карар белән билгеләнә.

Алимент бары тик акчалата гына түләнә. Ул билгеләнгән вакытта һәм башкару документында күрсәтелгән күләмдә түләнергә тиеш.

Бездә онлайн кабул итү бар. Суд приставлары федераль хезмәте идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстанның баш суд приставы урынбасары Елена Варфоломеева һәр айның беренче җомгасында кабул итә. Һәр кабул итүгә 30га якын кеше языла. Кабул итүгә «Телеграм» һәм «ВКонтакте» социаль аккаунтыбыз аша алдан язылырга кирәк.

Фикер

Мин – 1941 ел баласы. Үземнең балачагымны күңелле итеп истә калдырганмын. Без бик тату үстек. Мәктәп елларым да күңелемдә иң якты хисләр булып саклана. Җидееллык кына булса да, укытучыларыбыз безне бик яхшы укыттылар. Аларның берсе дә исән түгел инде. Үземә дә 80 яшь тулды. Хәзер, еллар узгач, бар да искә төшә. Гомерем буе Арча милли аяк киемнәре фабрикасы филиалында эшләдем. Җәй көне уракка йөри идек. Ничек арымаганбыздыр, кичке уенга да чыгарга хәлебез кала иде. Ял да иттек, эштән дә курыкмадык. Авылдашларым кайда гына эшләмәделәр. Яшелчә бакчасында да, тавык фермасында да тир түктеләр. Бик тә яшьлегемне сагынам. Их, ул чакларны кайтар иде!

Суфия БАҺАВЕТДИНОВА.
Биектау районы Ямаширмә авылы

Кемгә тиеш?

Фитыр сәдакасын авыруларга да бирергә мөмкин, диләр. Әмма аларның кайберсе дога кыла белми бит. Мондый очракта нишләргә соң? Фитыр сәдакасы кайсы көнне һәм кемнәргә бирелергә тиеш?

ФӘНИЯ

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм Хәйруллин:
– Фитыр сәдакасын мескен кешегә бирү кирәк. Биргәндә аңлатып: «Бу – минем фитырым, сез аны ризыкка тотыгыз», – диярге кирәк. Сәдаканы дога кыла белгән кешегә бирү саваплырак санала. Аны гаеткә кадәр бирергә кушалар. Әгәр аннан соң бирелсә, ул инде гади сәдакадан китәчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

2 май | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.45 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
06.45 «Ураза гаете мөбарәк булсын!» 0+
09.00 «Изге Рамазан» 6+
09.15 «УЕННАН УЙМАК 2» 12+
10.00 «Мөнәҗәт әйтәм» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 18.00 «Татар халык җырлары» 0+
12.00 «Татар сүзе» 6+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.30 «МУЛЛА» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Ураза гаете мөбарәк булсын!» 0+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КОРОЛЕВСТВО ПОЛНОЙ ЛУНЫ» 16+
23.50 «Соотечественники». Малика Гельмутдинова 12+
01.05 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 07.40, 01.45 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
06.45 «Ураза гаете мөбарәк булсын!» Турыдан-туры трансляция 6+
09.00 «Мөнәҗәт әйтәм». Концерт 6+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00 «Әй, мөселман, кыл гыйбадәт». Зөһрә Сәхәбиева җырлый 6+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Ураза гаете мөбарәк булсын!» 6+
13.05 «МУЛЛА» 12+
15.30 Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале 6+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
18.20 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «ЭЗЛӘДЕМ, БӘГЪРЕМ, СИНЕ» 12+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.15 «Әй, мөселман, кыл гыйбадәт». Зөһрә Сәхәбиева җырлый 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.40, 06.10 «ХИРОМАНТ. ЛИНИИ СУДЕБ» Многосерийный фильм (S) 16+
06.00 Новости
07.30 «ЕГЕРЬ» (S) 12+
09.20 «Ураза-Байрам». Трансляция из Уфимской соборной мечети
10.00, 12.00, 15.00 Новости с субтитрами
10.15, 18.20 Информационный канал 16+
12.20, 00.30 «Светлана Немоляева. Мы старались беречь друг друга» 12+
13.20 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ» 12+
15.15 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ» (S) 16+
16.35 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым 12+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». Новые серии (S) 12+
23.35 «Для всех я стал Фоксом» 12+
01.20 «Наедине со всеми» 16+
03.30 «Россия от края до края» 0+

РОССИЯ 1

05.00 «ДЕРЕВЕНСКАЯ ИСТОРИЯ» 12+
09.00 Праздник Ураза-Байрам. Прямая трансляция из Московской Соборной мечети
09.55 «По секрету всему свету»
10.15 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 21.00 Вести
12.15 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
14.55, 17.55 «АКУШЕРКА. НОВАЯ ЖИЗНЬ» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ЗОЛОТОЙ ПАПА» 16+
01.20 «ЛЮБОВЬ ПО НАЙМУ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.30, 14.55, 18.20, 21.20 Новости
06.05, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «ЗЕМЛЯК» 16+
12.35 «ГОНЩИК» 12+
15.00, 00.45 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
15.55 Хоккей. Выставочный матч. Россия – Белоруссия. Прямая трансляция
18.25 Мини-футбол. Чемпионат России «Парибет-Суперлига» 1/4 финала. КПРФ Москва – «Тюмень». Прямая трансляция
20.20, 05.10 «Громко». Прямой эфир
21.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Байер» – «Айнтрахт». Прямая трансляция
00.15 Тотальный футбол 12+
01.30 «Наши иностранцы» 12+
01.55 Классика бокса. Сонни Листон против Кассиуса Клэя 16+
02.40 Легкая атлетика. Эстафета «Весна Победы» 0+
03.05 Новости 0+
03.10 Хоккей на траве. Кубок России. Финал. Трансляция из Казани 0+

НТВ

04.40 «СИБИРЯК» 16+
06.10 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ» 16+
07.50, 08.20 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-2» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-3. ГУБЕРНАТОР» 16+
12.10, 16.20, 19.35 «ДИНОЗАВР» 16+
22.15. «Будут все!» Концерт Виктора Дробыша 12+
00.55 «ПЕРВЫЙ ПАРЕНЬ НА ДЕРЕВНЕ» 12+
04.25 Их нравы 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ПРОВОДНИЦА» 16+
06.40, 02.55 «ЕСЛИ НАСТУПИТ ЗАВТРА» 16+
13.10 «ОЛЮШКА» 16+
15.10 «КЛЕВЕР ЖЕЛАНИЙ» 16+
19.00 «ПЛАТЬЕ ИЗ МАРГАРИТОК» 16+
22.55 «ИЩУ ТЕБЯ» 16+
00.50 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
05.05 «ПРОВОДНИЦА» 16+
06.00 «СКАРЛЕТТ» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. УДАРНАЯ ВОЛНА»
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.30, 23.35 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Не факт!» 12+
13.50, 14.05, 03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Ступени Победы». «ПВО Москвы» 16+
21.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал 12+
22.30 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
22.55 «Скрытые угрозы». «Альманах №96» 16+
01.10 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
02.45 «Второй. Герман Титов». Док. фильм 12+

3 май | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты 6+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА» 16+
11.00 «Каравай». Музей уездного города 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЗАДАНИЕ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ. ОПЕРАЦИЯ «ТАЙФУН» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Халкыбыз мирасы». Концерт 6+
17.00 «КазАнга Казанда» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Вехи истории» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «КАК ВОСПИТАТЬ МУЖА» 16+
01.25 «Видеоспорт» 12+
01.50 «Соотечественники». Рашид Сюняев 12+
02.30 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «ҮКСЕЗЛӘР» 12+
09.40, 00.15 «Туган җир» 12+
10.30 «ЕГЕТ СҮЗЕ БЕР БУЛА»
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Дунай...» Татарстанның халык артисты Наил Дунаев турында телевизион очерк 6+
15.00 «УТ КҮРШЕЛӘР» 12+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
18.20 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.25 «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.50, 06.10 «ХИРОМАНТ. ЛИНИИ СУДЕБ». Многосерийный фильм (S) 16+
06.00 Новости
08.30 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 0+
10.00, 12.00 15.00 Новости с субтитрами
10.15, 18.20 Информационный канал 16+
12.20, 23.40 «Владимир Этуш. «Все, что нажито непосильным трудом» 0+
13.15 «БЕЛОРУССКИЙ ВОКЗАЛ» 0+
15.15 «СТРЯПУХА» 0+
16.30 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ» (S) 12+
00.40 «Татьяна Самойлова. «Ее слез никто не видел» 12+
01.25 «Наедине со всеми» 16+
02.50 «Россия от края до края» 0+

РОССИЯ 1

05.25 «БЫВШИЕ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «ОТ ПЕЧАЛИ ДО РАДОСТИ» 12+
14.55, 17.55 «АКУШЕРКА. НОВАЯ ЖИЗНЬ» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ХРУСТАЛЬНОЕ СЧАСТЬЕ» 12+
01.20 «НОВАЯ ЖИЗНЬ МАШИ СОЛЕНОВОЙ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 15.00, 21.40 Новости
06.05, 15.05, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «ЗЕМЛЯК» 16+
12.25 Художественная гимнастика. Прямая трансляция из Москвы
15.30 «КОНТРАКТ НА УБИЙСТВО» 16+
17.30 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet» Женщины. Финал. Прямая трансляция
20.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Л. Хант – Д. Риггс. Трансляция из США 16+
21.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/2 финала. «Вильярреал» (Испания) – «Ливерпуль» (Англия). Прямая трансляция
00.45 «Голевая неделя» 0+
01.10 Футбол. Кубок Либертадорес. «Стронгест» (Боливия) – «Атлетико Паранаэнсе» (Бразилия). Прямая трансляция
03.10 Классика бокса. Мохаммед Али. Лучшее 16+
03.45 Баскетбол. Парибет Чемпионат России. Мужчины. Суперлига-1. Финал. «Руна» (Москва) – «Уралмаш» (Екатеринбург) 0+
05.30 «Правила игры» 12+

НТВ

04.50 «БИТВА» 6+
06.05, 08.20 «МУЖСКИЕ КАНИКУЛЫ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20, 00.05 «АФОНЯ» 0+
12.10, 16.20, 19.35 «ДИНОЗАВР» 16+
22.30 Премьера. «Все звезды майским вечером» 12+
01.35 «МУЖСКИЕ КАНИКУЛЫ» 16+
04.40 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «СКАРЛЕТТ» 16+
13.10 «ИЩУ ТЕБЯ» 16+
15.10 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ» 16+
19.00 «ВЕРНАЯ ПОДРУГА» 16+
22.55 «КРОВЬ С МОЛОКОМ» 16+
01.00 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
02.55 «ЕСЛИ НАСТУПИТ ЗАВТРА» 16+
05.45 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.20, 23.35 «ДЕЛО РУМЯНЦЕВА» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Не факт!» 12+
13.50, 14.05, 03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Ступени Победы». «Битва за Москву» 16+
21.25 «Улика из прошлого» «Капитан Пауэрс. Тайна сбитого летчика» 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии» 12+
01.20 «РАЗМАХ КРЫЛЬЕВ» 12+
02.45 «Знамя Победы» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 2–8 МАЙ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Сак булыгыз: акчага бәйле хәйлә, алдашу булырга мөмкин. Кемдер бик вакытлы хәбәр җиткереп, сезгә ярдәм кулы сузачак. Атна ахыры көтелмәгән яңалыклар белән сөендерер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Атна башында кыенрак хәлләр килеп туар. Алардан чыгу өчен, шактый ук зур акыл һәм рухи көч таләп ителер. Шул ук вакытта эшегездә әйбәт керем вәгъдә иткән мөмкинлекләр барлыкка килер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Эштә акча һәм чыгым турында авыррак сөйләшү булмагае. Якын кешегез искиткеч шәп бер сюрприз белән сөендерер. Җитәкчегезнең кырысрак мөнәсәбәте үзегезгә дөп-дөрес нәтиҗә чыгаруга китерер.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Кызыклы вакыйгаларга бай һәм керемле чор. Дөрес, атна башында күңелегезне тырнап алган бер хәл булып алыр алуын. Ләкин шуннан соң шатлык-сөенечләрнең бер-бер артлы явып кына торуы аны шундук онытдырыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Бәйрәм арасында эштәге киеренкелек бераз гына нерв күзәнәкләрен талкып алырга мөмкин. Сәбәбе – икейөзле хезмәттәшләрегезнең сезгә аяк чалырга маташуы. Үзләрен күрмәмешкә, хыялларын белмәмешкә салышыгыз. Шулай икән, астыртынлык, көнчелек «кыр»ыннан җиңүче булып чыгачаксыз.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Акча янчыгы калынаеп китүгә өметләндерердәй яңалыклар ишетелер. Эштә бер мәсьәләдә үҗәтлек күрсәтергә туры килер. Бу берәүләрне тәмам гаҗәпкә салса, икенчеләр сезнең белән тизрәк дуслашу турында хыяллана башлар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Бу атна баш мие күзәнәкләрен актарып чыгарырдай дәрәҗәдә гаять катлаулы бурычларны хәл итүгә багышланыр. Сөенче: алар, чишелешләре табылу нәтиҗәсендә, ниһаять, мөһим эшләрегез исемлегеннән төшеп калыр. Якыннарыгыз белән мөнәсәбәтләрдә моңарчы күрелмәгән җылылык сизелә башлар.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Хафаланасы юк: бүгенге проблемаларыгыз якындагы берничә көн эчендә үк хәл ителеп бетәчәк. Кайберәүләргә бу атна отышлы бәядән бик кирәкле әйбер сатып алу мөмкинлеге белән истә калачак. Гәрчә вакыты матди әйберләр турында уйлау өчен бик үк уңайлы булмаса да...

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Нәни генә шатлык-сөенечләр, күңелгә хуш килердәй уй-кичерешләр белән тулы атна. Ләкин кемнәрнеңдер бик «акыллы» киңәшләрен колак читеннән генә уздырып җибәрү әйбәтрәк. Эчке сиземләвегез, фикер сөрешегез бик дөрес, шуларга таянсагыз, үкенмәячәксез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Кешегә өстән-өстән генә бәя биреп, нык ялгышуыгыз бар. Шуңа күрә бу мәсьәләдә саграк булыгыз, имеш-мимеш, гайбәт сүзләрдән читтәрәк йөрергә тырышыгыз. Бер яңалык эшегезгә бәйле зур хыялыгызны тормышка ашыруга өмет чаткылары уятыр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Югарырак хезмәт хакына өметләндерердәй хәлләр булып алыр. Үзегезне байтактан борчып килгән бер мәсьәләгә, ниһаять, ачыклык кертелер. Ләкин бу җәһәттән уйларыгызны әлегә тышка чыгармау хәерле, юкса кемнедер рәнҗетү куркынычы зур.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Белеп торыгыз: бүген начар кебек тоелган әйбер иртәгә уңышка ирешү ачкычына әйләнергә мөмкин. Бу җиде көндә акча мәсьәләсендә саграк булу кирәк: нәрсәнедер бутавыгыз яки «тигез җирдә» хаталануыгыз бар. Җитәкчегезнең үзегезгә карата хәерхаһлыракка әйләнүе өчен әйбәт кенә җирлек барлыкка килер.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, әтисе

ФӘННУР

озакка сузылган каты авырудан вафат булуы сәбәпле, хезмәттәшебез Гөлгенә Әүһәдиеваның һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әтисе

ВАСИЛЬЕВ
Николай Алексеевич

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Гражданлык җәмгыяте институтлары белән берлектә эшләү идарәсенең иҗтимагый-сәяси һәм коммерциясез оешмалар белән берлектә эшләү бүлеге баш киңәшчесе Лукашина Марина Николаевнаның авыр кайгысын уртаклаша.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАҺВӘГӘ ГЕНӘ ЫШАНЫЧ ЮК

Баш әйләнә, күңел болгана, аяклар тотмый... Түбән кан басымыннан интеккән һәркемгә таныш халәт бу. Аны дару һәм каһвә ярдәмендә җиңәргә өйрәнгән без. Белгечләр исә түбән кан басымына бармак аша гына карауның аянычлы нәтиҗәләргә китерү ихтималы турында кисәтә. Ул нәрсәсе белән куркыныч?

Терапевт-кардиолог, медицина фәннәре кандидаты, доцент Ленар КАШАПОВ түбән кан басымына бәйле сорауларга җавап бирде.

:: Ленар әфәнде, түбән кан басымының чиге кайда?

– Кан басымының 100/60тан түбәнрәк булуы артериаль гипотензия, икенче төрле әйтсәк, түбән кан басымы дип атала. Туганда ук түбән кан басымлы булган кешеләр бар. Алар кан басымы күрсәткечләре 100/60, 90/60 булганда да үзен яхшы хис итә. Озын буйлы, ябык кешеләр, спортчыларда еш кына артериаль гипотензия күзәтелә. Аларда бу халәт еш кына берниндн билгеләрсез уза. Артериаль гипотензия нәселдән дә килә ала. Түбән кан басымы организмның әйләнә-тирә мохиттәге үзгәрешләргә җавабы да булырга мөмкин. Әйтик, тауларга, субтропик, тропик климатка килеп эләккән кешенең кинәт кенә кан басымы төшә ала. Патологик гипотензия вакытында кешенең башы авырта һәм әйләнә, күңеле болгана, хәлсезлек күзәтелә. Ул еш кына нерв системасының кан күзәнәкләре эшчәнлеге начарлану сәбәпле килеп чыга.

:: Кисәк кенә кан басымы төшү нәрсәсе белән куркыныч?

– Андый чакта кеше аңын югалта. Моннан тыш, кан басымы кисәк кенә төшкәндә, кешенең йөрәк тибеше дә начарлана, аритмия күзәтелә. Моннан тыш ул ишемик инсультка да китерә ала.

:: Кан басымы нинди күрсәткечкә кадәр төшкәндә, кичекмәстән «ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк?

– Аның төгәл генә күрсәткече юк. Иң беренче чиратта кешенең үз-үзен ничек хис итүенә таянырга кирәк. Әгәр хәле начарлана барса, кан басымы 90/60тан да түбәнрәк булса, «ашыгыч ярдәм» чакыру хәерле.

:: Түбән кан басымыннан интеккән кешеләр ничек тукланырга тиеш?

– Бу төркемгә кергән кешеләрнең көндәлек туклану рационында сыр булырга тиеш. Аның составында терамин дигән матдә бар. Ул кан басымын күтәрә. Кан басымы түбән булганда куе чәй, каһвә дә ярдәм итә. Әмма алар белән артык мавыгырга ярамый. Ник дигәндә, бик тиз бәйлелек пәйда булачак. Туклану буенча башка чикләүләр юк.

:: Түбән кан басымы югарысына карaганда күпкә куркынычрак, диләр...

– Аларның икесе дә үзенчә куркыныч. Шулай да организмга озак вакыт тәэсир итү ягыннан, югары кан басымы (гипертония) күпкә куркынычрак. Гипотензия исә кан басымы кисәк төшкән мизгелдә генә куркыныч.

pixabay.com

:: Кан басымы түбән булган кешегә сөлек салдырырга, хиҗамә ясатырга ярыймы?

– Андый чикләүләр юк. Кан басымы түбән булган кешегә физик активлыкны арттыру – фитнес, җәяү йөрү, бассейнда йөзү, йөгерү дә файдалы булачак. Алар барысы да кан басымын җайга сала. Авыр әйбер күтәрү, озак кына хәрәкәтсез тору, утыру, киресенчә, кан басымын төшерә. Дөрес тукланган, һәрвакыт хәрәкәттә булган кеше түбән кан басымыннан даруларсыз гына да котыла ала.

:: Түбән кан басымы организмда нинди авырулар барлыгы турында кисәтә?

– Ул, иң беренче чиратта, нерв системасы авырулары, аерым алганда, кан тамырлары дистониясе турында кисәтә. Эндокрин системасында хилафлыклар булганда да, кешенең кан басымы түбән була.

:: Кан басымы кисәк төшмәсен өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

– Яткан, утырган җирдән кисәк торырга ярамый. Андый чакта кешенең башы әйләнә, ул хәлсезләнә, нәтиҗәдә, кан басымы төшә. Шуңа күрә ятып торган җирдән торырга уйласаң, башта утырырга кирәк. Кан тамырлары шушы халәткә ияләшергә өлгерсен. Басканда да шул ук кагыйдәне истә тотсагыз иде.

ХОЛЕСТЕРИН КҮТӘРЕЛГӘНДӘ НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

Ярый

* яшелчә ашлары;
* парда яки томалап пешерелгән майсыз балык, ит ризыклары;
* аз майлылыктагы сөт ризыклары;
* карабодай, солы ярмасы, тары боткасы;
* пешерелгән яки чи килеш яшелчәләр: кабак, ташкабак, баклажан, кәбестә;
* аз май салып болгаткан винегрет, салатлар;
* диңгез ризыкларының кайбер төрләре;
* ногыт борчагы, фасоль, коңгырт дөге.

Ярамый

* майлы ит, балык;
* иртән йомырка пешереп ашау;
* яңа пешкән икмәк, камыр ризыклары;
* төрле консервлар, эшкәртелгән ит, колбаса, сосискалар;
* майлы шулпалы ашлар;
* югары майлылыктагы сөт ризыклары;
* шоколад, куе каһвә һәм какао.

Үзем сынадым

МАШИНАДА КҮҢЕЛ БОЛГАНСА...

Машинада барганда, күңел болгана торган гадәтем бар. Соңгы арада тозлы кыяр булыша башлады. Юлга чыкканда, кисәкләргә турап, үзем белән алам. Күңел болгана башлауга, шуны ашап куйсаң, косасы килү бетә.

Фаилә ХӘКИМОВА. Саба

Яшәртә торган битлек

Бер йомырка сарысына 1әр чәй кашыгы каймак һәм алоэ согы кушарга кирәк. Битка шуны сөртеп, 20 минут тотарга һәм салкын су белән юарга. Бу битлекне 20 көн рәттән ясарга ярый. Ул бит тиресен яшәртә, чистарта.

Һәр чәйнең – үз шифасы

ВИТАМИНЛЫ ЧӘЙ. Ул тигез өлешләрдәге гөләп, миләш, нарат җиләге, кура җиләге, карлыган һәм шул ук җиләкләрнең яфракларыннан ясала. 1–2 кашык катнашманы 2 стакан кайнаган суда пешерергә, 10 минут тагын кайнатырга һәм өсте капланган савытта 4 сәгать тонәтергә, салкынча, караңгы урында суытырга, марля аша сөзеп, тәменчә шикәр салып, көнгә 3 тапкыр яртышар стакан эчәргә.

ТЫНЫЧЛАНДЫРА ТОРГАН ЧӘЙ чабыр үләне, аю баланы, әрем, әспе, мәтрүшкә, кызыл дуләнә, туран уты (укроп), колмак, дару мелиссасы, кандала үләне, бөтнек, күкчәчәк, ромашка катнашмасыннан ясала. Хуш исле булсын өчен, гөлҗимеш һәм башка җиләкләр өстәргә мөмкин.

ЭЧ КИТКӘНДӘ ЭЧӘ ТОРГАН ЧӘЙ. Ул 3 өлеш шомырт, 2шәр өлеш чия, 1әр өлеш кырлыган тамыры, әнеч чәчәге, әнеч җимеше һәм 3 өлеш шалфей яфрагы кушып ясала. 2 аш кашыгы катнашмага 2 стакан кайнар су салып пешерәләр, 10 минут кайнаткач, марля аша сөзеп, көнгә 3–4 тапкыр, ашарга 15 минут кала яртышар стакан эчәләр.

Белә идегезме?

Тиздән юл читләрендә анда-санда бака яфраклары күренәчәк. Яралары яхшы төзәтүеннән тыш, бик күп чирләрдән котылырга да ярдәм итә ул. Бака яфрагы төнәтмәсе ютәлдән файдалы, сулыш юлларын да киңәйтә. Аның өчен яфракларны җыеп, иттарткыч аркылы уткәрергә кирәк. Бер бал кашыгы боламыкны бер бал кашыгы балга кушып эчәргә киңәш ителә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара
ЗИННӘТУЛЛИНА

40тан соң кимәскә...

Май бәйрәмнәрендә бакча, йорт эшләре турында гына уйлап, үзебезне онытып җибәрмәсәк иде. Озынозак яллар – гардероб яңарту, булганын рәткә китерү өчен дә менә дигән вакыт.

Стилист-имиджмейкер Ленизa ЧИРСКОВАның быелгы язгы-җәйге мода, дөрес киенү буенча киңәшләре сезгә файдага булыр.

:: Ленизa, 2022 елның язында һәм җәендә нинди төсләр модада?

– Быел салават күперенең бөтен төсләре дә модада: янып торганыннан башлап, әлеге төсләрнең «пастель» тоннарына кадәр. Бигрәк тә шәмәхә (лаванда төсе), яшел, кызгылт сары, фуксия, зәңгәрсу төсләрне сайласагыз, бик күркәм күренерсез.

:: Һәр 20 ел саен мода кабатлана, диләр. Бу чыннан да шулаймы?

– Әйе, бу чыннан да шулай! Мода цикллы. Трендлар ни өчен һаман үткәнгә кайта, дисезме? Чөнки уйланыласы инде уйланылып беткән. Мода – музыка, рәсем сәнгате төсле үк мәдәниятнең бер төре. Ә мәдәниятка шулай ук «үткәнгә кайту», циклылык хас. Һәр яңа нәрсә – онытылган иске ул. Ләкин тренд үзгәрми генә әйләнеп кайта дигән сүз түгел. Һәр бер «ретро дулкын» замана мәдәнияте һәм җәмгыятькә яраклашып кире кайта.

:: Һәр хатын-кызның гардеробында булырга тиешле киемнәрне атап үтсәгез иде.

– Мин хәзер санап үтәчәк киемнәр трендларга бәйле түгел. Алар һәрвакыт актуаль һәм һәр хатын-кызны матур һәм яшь күрсәтә.

▸ **Чалбарлы костюм.** Төслеме, әллә база төсендәме – анысы әһәмиятле түгел. Ул һәрвакыт затлы, элегант һәм стильле.

▸ **«Косуха» куртка.** Эвелина Хромченко сүзләре белән әйтсәк, ул – хатын-кыз гардеробындагы яшәртә торган «крем». Бунтарьлык һәм кискенлек өсти. «Косуха» – гардеробтагы база кием, ул беркайчан да модадан чыкмый.

▸ **Ирләр стилендәге күлмәк.** Әлеге кием көн саен кию өчен бик уңай, шулай ук гардеробтагы база булып тора.

▸ **Зәңгәр джинс чалбар.** Ул балтыр өлешендә иркен булып торырга тиеш. Ягъни леггинсы төсле сыланып торырга тиеш түгел.

▸ **Ак кеды.** Гардеробтагы теләсә кайсы яшьтәге һәркем өчен һәрвакыт кирәкле әйбер.

▸ **Тренч.** Тренч пальто функциясен үти, тик ул җәйге һәм җиңелчә генә.

:: Бу сезонда нинди модалы тенденцияләр күтелә?

– Яңалыкларга килгәндә, бил сызыгы түбән (заниженная талия) киемнәр заманча гардеробта урын ала. Шулай ук мини-итәк, хатын-кызга нәфислек өсти торган итәктәге озын ерыклар, каурый детальләр һәм силуэтлардагы «кисемнәр» (бил өлешендәге ачыклыклар) быел модада.

:: Кырыктан соң нинди киемнәрне кимәвең яхшырак?

– Хәзер стильдә яшь үзенчәлегенә бәйле төгәл формулалар юк. Хатын-кызның ничә яшьтә булуына карамастан, яшь күренергә, башкаларны да үзенең матурлыгы белән илһамландырырга хакы бар. Шунысы мөһим: 40тан соң антитрендлар кимәсәгез иде. Аларның кайберләрен санап үтәм.

▸ **Леопард.** Аны кырыктан соң тиешенчә кулланмау җилбәзәк кыяфәт бирә. Бигрәк тә леопард лосиналар, бизәкле сыланып тора торган джинсылар кимәскә киңәш итәр идем.

▸ **Ялтыравык, бизәкле трикотаж киемнәр.** Яшь барган саен, хатын-кызлар «кыйммәт, бай» дигән эффектны ярата, әлеге «мәхәббәт»егездән баш тартсагыз, яхшырак булыр.

▸ **Шакмаклы озын итәк.** Бу – тагын бер көточкыч хата, ул нәкъ менә кырыкны узган хатын-кызларда күзәтелә.

pixabay.com

Идәнгә кадәр төшеп торган шакмаклы итәк кимәскә тырышыгыз.

:: Офиска кию өчен өс һәм аяк киемендә нинди төсләрне куллану дөресрәк булыр? Офис киеменә чәчне янып торган төрле төсләргә буяу туры киләме?

– Хәзерге заманда офис киемнәре өчен катгый таләпләр юк. Мин шәхсән офис киемнәре өчен «ирек» булса да, дресс-код кагыйдәләрен онытып җибәрмәскә кирәк дип саныйм. Төсләрне сезонга бәйләп сайларга киңәш итәр идем. Яз һәм җәй өчен кием сайлаганда, быел модада булган төсләрнең пастель тоннарын сайлау дөрес булыр. Ертык джинс һәм янып торган төрле төстәге футболка белән эшкә килүгә караганда, мондый киемнәр зәвыклы, эшлекле, элегант кыяфәт бирәчәк. Чәчләргә килгәндә, хәзер аны төрле төстәге акцент белән буяу бик актуаль. Шуңа күрә монда барысы да индивидуаль, шәхси гардеробка карарга кирәк. Хатын-кыз бит яңалык ярата, шунлыктан чәчне янып торган төрле төсләргә буяу – кәеф күтәрү, башкалардан аерылып тору өчен менә дигән исул.

:: Кайсы дөресрәк: бер кыйммәтле кием алумы, әллә берничә арзан кием сайлаумы?

– Бүген аңлы куллануга таянып эш итү дөресрәк. Нәрсә булса, шул булыр дип, уйламаган сатып алулардан сакланыгыз. Гардеробыгызда үзегезгә туры килгән киемдә 3–4 образ булса, бик яхшы. Ә киемнең кыйммәтле яки арзанлы булуы һәркем өчен индивидуаль, аны һәркем үзе хәл итә. Стильле киенү – кыйммәтле киенү дигән сүз түгел. Арзанлы гардеробны да зәвык белән җыярга була. Мин һәр хатын-кызга үзләренең тышкы кыяфәтләрен камилләштерүләрен, үзләрен яратуларын һәм матур киемнәр белән куандыруларын теләп калам.

Тәмле булсын!

Шашлык

Алсу ЗАРИПОВА рецептлары

- 2 кг тавык итенә 200 мл кефир, бер лимон согы, 1 туралган лимон, боҗралап туралган бер зур баш суган һәм тәменчә тоз белән борыч салып, салкынча урынга куярга. Бер сәгатьтән шашлыкны пешерергә дә була.
- 1 кг тавыкның түш итенә 2 аш кашыгы соя соусы, 1 аш кашыгы бал, 1 чәй кашыгы гәрчич, 2 аш кашыгы майонез, тәменчә тоз һәм борыч салып, бер сәгатькә салкынча урынга куярга. Шашлыкны агач таякларга тезеп, мичтә яки мангалда пешерергә була.
- 1,5 кг сыер итенә 300 мл газлы минераль су, 1 данә ачы борыч, 2 баш суган, 2 аш кашыгы майонез, тәменчә тоз һәм борыч салып болгатырга. Шашлыкны ике сәгатьтән пешерергә мөмкин.

КРЫЖОВНИК ЯШӘРӘ

Крыжовник җимеш бирүдән туктаса, димәк, ул картайган. Әмма аны яшәртергә мөмкин. Моның өчен өч ел дәвамында һәр ел саен куагының өчтән берен төбеннән кисеп алыгыз. Шулай эшләгәндә аның бер өлеше яңара, икенче өлеше җимеш бирә тора.

КЫЧЫТКАН ЧӘЧНЕ НЫГЫТА

Чәч коелудан интегүчеләргә яшь кычыткан суы ярдәмгә килер. Моның өчен кычытканны кайнап торган суга салып, 5 минут кайнатып алыгыз. Суынгач, сөзеп, юылган чәчне әлеге су белән чайкарга. Атнасына 2–3 тапкыр куллансагыз, нәтиҗәсе озак көттермәс.

Бакчачыга

СУГАН УТЫРТУ СЕРЛӘРЕ

✓ Суганны туфрак өлгереп, берәз җиллләгәч, май башында утырталар. Иртә утырткан очракта, салкын тиеп, «мулла»ланырга – көпшә җибәрергә мөмкин.

✓ Орлык суганның уртача зурлыктагысын (диаметры 14–21 мм) сайласагыз оттырмассыз.

✓ Аны гел бер урынга утыртмагыз. Суганны алдагы елны помидор, кәбестә, борчак, ташкабак үскән түтәлләргә утырту яхшы.

✓ Утыртканчы, суганның башларын (өске өлешен) берәз кисеп чыксагыз, ул тизрәк тишеләчәк.

✓ Утыртыр алдыннан, суганны берәз тоз һәм марганцовка салынган суда 2–3 сәгать тотып алыгыз. Аннары чайкап алсагыз да яхшы. Бу аның авыруларга каршы торучанлыгын арттыра.

КӨН ДӘ МЕҢ СОРАУ

Көнкүрешебездә һәрдаим мең төрле сорау туып тора. Кайсыларына җавапны диннән дә эзләргә күнектек. Сәхифәбезнең чираттагысын укучыларыбыздан килгән сорауларга багышларга булдык.

Саба районының Сатыш авылы имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ укучыларыбыз сорауларына җавап бирде.

?Кеше үлгәч, өйдә берничә көн ашарга ярамый, диләр. Бу дөресме?
ГӨЛИЯ. Мамадыш

Гадәттә, өйдә бу вакытта мәшәкать күп була. Кеше бик интегеп, авырып үлгән булырга мөмкин, шул рәвешле өйдә ис тә булуы бар. Ризыкка мохтаҗлык кичерү дә ихтимал. Бездәге гадәт буенча, үлем ишек каккан йортта ашамыйлар. Йә күршеләре чакыра, йә башка җиргә баралар.

?Сул кул белән ашарга ярамый, диләр. Ә сулагайларга нишләргә?
ДИНАР. Казан

Пәйгамбәребез (с.г.в.) уң кул белән ашарга куша, чөнки сул кул белән шайтан ашый. Сулагай булган кешегә нишләргә? Уң кул белән ашарга өйрәнергә тырышырга кирәк. Сәхабәләр дә үзләренең ризыкка сул кул белән үрелүен күргәч, уң кулына алмаштырган. Күпчелек очракта эчәк, ашказаны авырулары белән авырыйбыз. Нигә, дисезме? Чөнки ризыкны пәйгамбәребез (с.г.в.) өйрәткәнчә кабул итмибез.

?Кайберәүләр намазны үз вакытында укымый. Җыеп укырмын әле, дип кенә әйтәләр. Болай дөресме?
Исемемне күрсәтмәсәгез иде

Юк. Намаз – Аллаһы Тәгаләнең әмере. Эш вакытында да кемдер нәрсәгәдер бүленеп ала бит. Шул ук телефонда утыру өчен генә дә ничә тапкыр бүленәбез. Эш урыныңда, ярамаса да, тәмәке тартып алабыз. Шулар урынына тәһарәт алып, намазны башкарсак, хәерлерәк бит. Намазны вакытында уку дөресрәк. Нинди генә эш булса да, кеше үз тормышын намаз арасына көйләргә тиеш, һич кенә дә намазны эш арасына түгел!

Әгәр бөтенләй дә намаз укырга мөмкинлек юк икән, каза кылып, җыярга була. Вакытында укылган намаз өчен Аллаһы Тәгалә әҗерен дә, күп итеп бәрәкәтен дә бирәчәк. Намаз – Аллаһы Тәгалә белән кеше арасындагы элемтә ул. Намазга олы игътибар бирү – фарыз гамәл. Аның һәркайсының үз вакыты бар. Җан исә үзенә дигән ризыкны вакытында алырга тиеш. Вакытында ашыйбыз, даруны да, уколны да үз вакыты җиткәч кадыйбыз бит.

?Мәһәр бүләге итеп, булачак иремнән йорт сорый аламмы?
ЧУЛПАН. Казан

Аның күләме билгеләнми. Кәләш булачак иренең мөмкинлегенә карап сорарга тиеш. Элегрәк кыз кеше егеткә кияүгә чыгарга теләмәсә, мәһәрне күтәрә алмаслык күләмдә сораган. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Хатын-кызлар арасында иң хәерлесе, бәрәкәтлесе – мәһәре җиңел булган хатын-кыз!» – ди. Мәһәр ике якка да гарантия бирә торган булсын иде. Дөнья булгач, төрле хәл була. Ир ташлап китәргә, йә үләргә мөмкин. Хатын-кызга бирелгән мәһәр исә аерылышканнан яки ире үлгәннән соң башкага кияүгә чыкканчы (гыйддә) ашап-эчеп, көн күрерлек мал күләмендә булырга тиеш.

?Мөселманга йолдызнамә укырга ярыймы? Ышанмасам да, кайчакта укыйсы килә, кызык бит. Кайчагында туры да килә әле ул.
ЛӘЙСӘН

Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә, пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә дә барысын да билгеләде, күрсәтте. Бар кешенең дә язмышы – Аллаһы Тәгаләнең кулында, аннан кала берәү дә берни дә белмәс. Кешедән яшерелгән берничә гыйлем бар. Киләчәгебез турында фараз да – шул гыйлемнең берсе. Сихер, күрәзәчелеккә, йолдызнамәләргә ышану исламда катгый тыелган. Моңа ышанмасак хәерлерәк. Рәсүлебез: «Алдан күрүчеләргә барып, алар белән кызыксынса, аларның 40 көн укыган намазы кабул булмас, ә аларга ышанучы Аллаһы Тәгаләгә һәм пәйгамбәребезгә (с.г.в.) ышанмый», – ди. Нәрсәгә ышансаң, шул була бит. Ә Аллаһы Тәгалә безгә иң хәерлесен бирәм, диде. Шуңа ышанырга кирәк.

?Азан әйткәндә, эштән туктап торырга кушалар. Бу ник алай икән? Туктамасаң, гөнаһмы?
АЛИЯ. Балык Бистәсе

Моның хикмәте бар. Азан вакытында Аллаһы Тәгаләнең бөеклеге, аның барлыгы һәм берлегенә ышану, пәйгамбәребез (с.г.в.) Аллаһының рәсүле икәнен шәһадәт итү, намазга ашыгу, бәхетсезлектән котылып, бәхеткә омтылу турында сүзләр әйтелә. Мөселман өчен иң мөһим сүзләр яңгырый. Шуңа да, мөмкинлек булганда, туктап тору кирәк. Мәзин: «Хәййә гәләссаләәһ», – дигәч, «Ләә хәүлә үә ләә ку үәтә илләә билләәһил-галий’йил-газыйм», ягъни «Нәрбер хәл һәм куәт – олуг Аллаһы Тәгаләдән генә», – дип әйтү хәерле булыр.

Мәзин: «Хәййә гәләл-фәләәһ», – дигәч, «Мә шә әллаһу кәнә үәмә ләм йәшә ләм йәкүн», ягъни «Аллаһы Тәгалә теләгән эш һич булмый калмас һәм Ул теләмәгән эш һич булмас», – дип әйтү дә дөрес.

Мин – башка дин вәкиле. Әмма ислам динен кабул итәргә телим. Эшне ничек һәм нидән башларга?
Исемем редакция өчен генә

Иң элек – мәчеткә барырга. Имам белән сөйләшергә кирәк. Йә булмаса район мөхтәсибенә мөрәҗәгать итәргә. Казыйлар бар. Дуния нәзарәтендә дә киңәш бирерләр. Шәһадәт әйтеп, кеше ислам динен кабул итә ала. Оялмагыз! Бу – кеше тормышындагы бик җитди адым. Имам барысын да аңлатыр.

?Хәнәфи мәзһәбендә ир-егетләрнең сакаллары нинди озынлыкта булырга тиеш?
ИНСАФ. Саба

Сакалның озынлыгы – бер тотам. Сакалны, чәч һәм тырнак шикелле үк, тәрбияләп, матурлап тоту хәерле. Милләтебездә дә, динебездә дә чисталык-пөхтәлек югары дәрәҗәдә тора. Шуңа да мөселманга матур, чиста йөрергә кирәк.

?Берәү кешенең серен сөйли дә: «Кешегә әйтмә инде, сиңа гына әйтәм», – дип куя. Бу гайбәт саналамы?
РУМИЯ. Арча

Серне әманәт итеп сөйлиләр икән, аны башкаларга тарату тиеш түгел. Кеше серен башкага сөйлибез икән, без сере белән уртаклашкан кешегә хыянәт итәбез. Бу бик начар. Гөнаһ та. Бу эш белән мавыкмасак иде. Сер саклый алмавыгызны беләсез икән, алдан ук кисәтергә кирәк.

Май аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Якш	00:43	04:00	16:52	19:21	21:46
2	Дүш	00:35	03:58	16:53	19:23	21:50
3	Сиш	00:26	03:56	16:54	19:25	21:54
4	Чәрш	00:14	03:54	16:56	19:27	21:59
5	Пәнҗ	23:55	03:52	16:57	19:29	20:59
6	Җом	01:49	03:49	16:58	19:31	21:01
7	Шим	01:47	03:47	16:59	19:33	21:03
8	Якш	01:45	03:45	17:00	19:35	21:05
9	Дүш	01:43	03:43	17:01	19:37	21:07
10	Сиш	01:41	03:41	17:03	19:39	21:09
11	Чәрш	01:39	03:39	17:04	19:41	21:11
12	Пәнҗ	01:37	03:37	17:05	19:43	21:13
13	Җом	01:35	03:35	17:06	19:45	21:15
14	Шим	01:33	03:33	17:07	19:47	21:17
15	Якш	01:32	03:32	17:08	19:48	21:18
16	Дүш	01:30	03:30	17:09	19:50	21:20
17	Сиш	01:28	03:28	17:10	19:52	21:22
18	Чәрш	01:26	03:26	17:11	19:54	21:24
19	Пәнҗ	01:25	03:25	17:12	19:56	21:26
20	Җом	01:23	03:23	17:13	19:57	21:27
21	Шим	01:21	03:21	17:14	19:59	21:29
22	Якш	01:20	03:20	17:15	20:01	21:31
23	Дүш	01:18	03:18	17:16	20:02	21:32
24	Сиш	01:17	03:17	17:17	20:04	21:34
25	Чәрш	01:15	03:15	17:18	20:06	21:36
26	Пәнҗ	01:14	03:14	17:19	20:07	21:37
27	Җом	01:13	03:13	17:20	20:09	21:39
28	Шим	01:11	03:11	17:20	20:10	21:40
29	Якш	01:10	03:10	17:21	20:12	21:42
30	Дүш	01:09	03:09	17:22	20:13	21:43
31	Сиш	01:08	03:08	17:23	20:15	21:45

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Ураза көндәлеге



Рамазан ае уразасына бәйле сораулар әле дә борчып тора. Шулардан берсе – казага калган ураза турында.

Рамазан ае беткәч, башта каза уразаларны тотаргамы, әллә шәүвәл ае уразасына керергәме?

Шәүвәл аенда 6 көн дәвамында ураза тоту – сөннәт. Рамазан ае беткәч, башта бу айда тота алмый калган уразаны тотып бетерергә тиешбез. Әлеге уразаны шәүвәл аенда тотсагыз, сез шәүвәл уразасын да тоткан булып саналачаксыз. Әлбәттә, башта рамазанда калган уразаны тотып бетереп, аннан шәүвәлнең алты көнен дә тотарга мөмкин.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АЙРАТ ЗАКИРОВ:
«ҮЗЕҢ ТЫРЫШМАСАҢ, ФАМИЛИЯ ГЕНӘ БУЛЫШМЫЙ»

Бүген «Ни хәл?» сәхифәсенә танылган җырчылар Люция Мусина һәм Рөстәм Закировның талантлы улы Айратны чакырдык. Оста итеп бии-бии саксофонда уйный ул. Аның белән үзенчәлекле инструмент, эти белән ул мөнәсәбәтләре, эстрада турында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Аллага шөкер. Казан музыка көллиятен тәмамлыйм быел. Әле менә мәш килеп имтиханнарга әзерләнәм.

:: Шактый үзенчәлекле инструмент сайлагансың. Ни өчен нәкъ менә саксофон?
– 4–5 яшьлек чагым булды микән, әни белән ниндидер музыкаль канал караганда күреп алдым мин аны. Аннары музыка мәктәбендә укый башладым. Башта флейтада уйнарга өйрәндем, 12 яшьтә саксофонны үзләштерә башладым. Нәкъ менә саксофонны сайлавыма эти бик сөенде. Баян классына йөргән булсам, инструментны аңа күтәрәсе булыр иде бит. Ә саксофон – җиңел инструмент, күтәрдең киттең, бер мәшәкате юк.

Ләкин ул чакта мин музыкант түгел, футболчы булу турында хыялланa идем. 14 яшемә кадәр уйнаганнан соң, футболны ташларга туры килде. 9 нчы сыйныфны тәмамлап, кайда да булса укырга кирәк иде. Менә шул чакта мине танылган саксофончы Артур Маузер, төгәлрәк әйтсәк, аның иҗаты музыка юлын сайларга илһамландырды. Мин Казан музыка көллиятенә укырга керергә әзерләнә башладым.

:: Эстрадага ничек кереп киттең?
– Көллияттә укый башлауга ук, татар эстрадасында эшләү теләге барлыкка килде. Шул теләгемне чынга ашырыр өчен, бик тырыштым, көненә 5–6 сәгатьләп шөгыльләндем.

Россия Туроператорлар ассоциациясенең аналитика хезмәте мәгълүматларына ышансаң, быелгы май бәйрәмнәренә чит илләргә тур бәяләре рекорд куйган. Билгеле булганча, Төркия, Мисыр, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм Абхазия – россиялеләр арасында иң популяр илләр. Шушы илләрдә берәр атна ял итүнең ничә сумга чыгасы ачыкланган. Әйтик, Абхазиягә сәфәр кылу ике кешегә 64 меңнән башлана. Бу – иң арзан вариант. Мисыр белән Төркия кунакларны 170 мең сумга кабул итәргә әзер. Ә иң кыйммәтле ялыгызны Сейшел утрауларында 521 мең сумга уздыра аласыз.

Россиядәге ялның күпмегә төшәсе дә билгеле. Бездәге курортларда 10 көн ял итү уртача 53 мең сум тәшкил итә икән.

Алай да, чит илдә ял итәргә җыенучылар бөтенләй үк юк түгел. «ПромРейтинг» аналитика агентлыгы уздырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, республика халкының 15 проценттан артыгы җәйге ялын чит илләрдә уздырырга ниятли. Иң популяр юнәлешләр – Төркия һәм Мисыр. Сораштыруда катнашучыларның яртысы диярлек җәй айларын дача-бакчаларда уздырырга җыена.

Казанны сайлыйлар

Майның беренче көннәрен авылда уздыру безнең өчен язылмаган кагыйдә кебек инде ул. Без авылларга таралышкан арада, шәһәрләр буш тормас үзе. Әйтик, Казан кунакханәләрендә майның беренче өч көненә урыннар бөтенләй калмаган. 7–10 майга туры килә торган ял көннәренә дә кунакханә номерларының 85 проценты инде буш түгел. Бу хакта Татарстанның туризм буенча Дәүләт комитеты башлыгы Сергей Иванов хәбәр итте. «Сезон буена ничә турист киләчәген әлегә әйтә алмыйм. Май бәйрәмнәрен уздырып җибәрик, шуннан соң күз күрер. Кунаклар күп килер дип уйлыйм», – диде ул.

Быелниләр көтелә?

Татарстан ел саен кунаклар кабул итәргә һәм үз халкын ял иттерергә ныклап әзерләнә. Быел да җәй үзенчәлекле вакыйгаларга бай булырга охшап тора. Мисал өчен, 2–5 июньдә Болгарда Vanlifefest автотуризм фестивале, 15–18 июльдә Алабугада Борис Березовскийның «Летние вечера в Елабуге» халыкара музыка фестивале, 6–8 августта шушында ук традицион Спас ярминкәсе, 13–14 августта урта гасыр сугышларына багышланган «Бөек Болгар» (Болгар шәһәрендә) фестивале узачак.

Тагын бер яңалык: быел «Казан – Зөя» һәм «Казан – Юдино» маршрутлары буенча узган гасырда ясалган паровозларда сәфәр кылып булачак. Билгеле, ретро-паровозларны яхшылап тикшермәгән килеш юлга чыгармаячаклар.

Кешбэклы ял

Үзебездә генә ял итүнең тагын бер уңай ягы бар бит әле. Россиядә ил буенча сәфәр-сәяхәтләр өчен тотылган акчаның бер өлешен кайтаруга көйләнгән «Туристик кешбэк» программасы эшли. Бу программа нигезендә билет яисә тур өчен «Мир» картасы белән түләргә кирәк. Шул очракта тотылган акчаның 20 проценты кире кайтачак.

«Туристик кешбэк»ның чираттагысы 18 гыйнвардан 12 апрельгә кадәр дәвам итте. Шушы аралыкта 2,5 млн россиялегә 8,5 млрд сум акча кире кайтарылган. Бу хакта Россиянең вице-премьеры Дмитрий Чернышенко хәбәр итте. Ул шулай ук «Туристик кешбэк»ның көзге-кышкы туристик сезонда да эшләячәген белдерде.

Әйткәнебезчә, бу программаны Россия буенча сәяхәт иткәндә генә кулланып була. Инде иң популяр шәһәрләр исемлеге дә билгеле. Кунакханәләр броньлау процентына нигезләнгән статистикага күз салсак, Казан – дүртенче урында. Ул бары Санкт-Петербург, Мәскәү һәм Сочидан гына калыша.

Сәяхәт өчен акча кайтарырга өлгермәгән булсагыз, балаларыгызның ялын кайгыртырга соң түгел әле. Балаларның җәйге ялына тотылган акчаны да кире кайтарып була. Әлеге программага Татарстанның 120дән артык лагере кертелгән. Аларга юлламаны шулай ук «Мир» картасы белән алу зарур. Шул очракта тотылган акчаның яртысы (бу сумма 20 мең сумнан артмаган очракта) кире кайтарылачак. Әлеге мөмкинлектән 1 майдан алып 30 сентябрьгә кадәр файдаланырга була.

«ТНВ» телеканалы алып баручысы Фәйрүзә Мәҗитова әлеге программа турында Россия Президенты Владимир Путин сөйләгәннәрдән ишеткән.

– Юлламаны Казан яны лагерьларына алдым. Берсе – «Заречье», икенчесе «Костер» лагере. Икесе дә – 18әр көнлек сменалар. Балаларга бик ошый, барасылары килеп тора. Биш мәртәбә ашаталар, программалары тыгыз, чаралар күп, – диде ул.

Быел Татарстанда 2020 елдан бирле эшли торган «1001 ләззәт» туры да дәвам итәчәк. Аны «Визит Татарстан» тәкъдим итә. Ике көнгә исәпләнгән әлеге турга җыенсагыз, 10 «ләззәт» арасыннан (алар арасында Болгар, Саба, Балык Бистәсе, Чистай, Мамадыш, Арча, Кама Тамагы, Алабуга, Алексеевск һәм Кукмара бар) берсен сайлыйсыз да ике көнлек сәфәргә кузгаласыз. Тур бәясе (кунакханәдә номер, ашау-эчү, экскурсия программасы белән бергә) бер кешегә 2700 сум тәшкил итә, балаларга ташлама да каралган.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САН

Хәзерге вакытта республикада **4500** урынга исәпләнгән **287** ял итү объекты (глэмпинг һәм кемпинглар, ял базалары, шәһәр яны кунакханәләре һ.б.) бар. 2022 ел ахырына кадәр тагын 34 объект ачарга җыеналар. Әйтик, яңа кемпинглар, ягъни палаткалы ял өчен урыннар Лаеш («Семрук»), Балык Бистәсе («Дикая ферма»), Мамадыш («Фиш глэмп берсут»), Югары Ослан («Свияга глэмп», «Форрест») һәм Баулы («Аул да ял») районнарында барлыкка киләчәк. 2021 елда республикадагы ял итү объектлары 20 меңнән артык кешене кабул иткән булса, быел 75 меңләп кунак көтәләр.

Татарстанның һәркем барып күрергә тиешле биш районы
«КАЗАНЬ ИНТЕРЕСНАЯ» БЛОГЫ АВТОРЫ РУСИНА СЕМЕНЕНКО МАРШРУТЫ

Чистай районы
Бу шәһәр ачык һавада урнашкан тулы бер музейны хәтерләтә. Монда Скарятин бакчасы һәм шул бакчадан ерак түгел Борис Пастернакның Мемориаль музее бар. XIX гасырдагы Чистайга сәяхәт итәргә теләүчеләр Өяз шәһәре музеен күреп чыгарга мөмкин. Бәясе – өлкәннәр өчен 550 сум, балалар өчен – 400 сум. Чистай Талкыш манарасы белән дә данлыклы. Монда шулай ук Каманың сул як ярында, Чистай шәһәре тирәсендә урта гасырларга караган Җукәтау (Юкәтау) шәһәрлеге калдыклары саклана. Аның хәрабәләре Чистайдан 3–4 чакрым көнбатышта Крутая Гора авылы янында урнашкан.
Ничек барып җитәргә? Чистайга көн саен диярлек автобуслар йөреп тора. Билет бәясе – 250–300 сум. Юл 2,5–3 сәгатьне алачак. Үз машинагызда барырга телисез икән, Казаннан Чистайга ике сәгатьтә барып җитеп була.

Саба районы
Монда килгәч, Русина Саба елгасы буена төшәргә киңәш итә. Саба районында данлыклы Миңгәр авылы, Нургали Миңнеханов исемендәге дендрарий, урман музее, Сатыш авылында урнашкан борынгы мәдрәсә – шулай ук игътибарга лаек урыннар. Дендрарийда, мәсәлән, 524 төрле агач-куаклар, җиләк-җимеш культуралары исәпләнә. Банан, инжир, ананаслар – барысы да үсә икән биредә. Кыскасы, көньякка барып торасы да юк.
Казаннан Сабага 1,5–2 сәгатьтә автобуста барып җитәргә мөмкин. Билет бәясе – 250 сум. Үз машинасында сәфәр кылучылар 1–1,5 сәгатьтә барып җитәчәк.

Алексеевск районы
Монда килгәч, туку фабрикасын күрми китмәгез. Россиядә сакланып калган ике туку фабрикасының берсе ул! 1927 елда ук ачылган әле тарихи бинада туристлар өчен музей да эшли. Алексеевскида атаклы химиклар династиясе – әтиле-уллы Арбузовларның музей-йорты да бар. Анда шулай ук танылган галим Александр Бутлеров тормышы белән дә танышырга мөмкин. Билярдәге «Изгеләр чишмәсе»н дә бер булса да барып күрергә куша Русина. Хуҗалар тавы белән әлеге чишмә төрле дин кешеләрен үзенә тарта.
Казаннан Алексеевскига көн саен автобуслар йөреп тора. Билет бәясе – 200–400 сум.

Кукмара районы
Кукмара, беренче чиратта, үз «каньоны» – Кызыл тавы белән данлыклы. Зур Кукмара авылы янында Нурминкә елгасы буенда урнашкан комлы калкулыклар Аризонаны хәтерләтә. Тарих сөючеләр 1870 елларда ук төзелгән абыйлы-энеле Комаровлар йортына һәм Мәчкәрәдә 1791–1793 елларда салынган борынгы җәмигъ мәчетенә рәхим итсен. Шулай ук монда, Ятмас-Дусай авылы тирәсендә күпгасырлык имән үсә. Биеклеге – 24 метр, ә юанлыгы 5 метрга якын бу имән бер кочакка гына сыймас!
Казаннан Кукмарага барып җитүнең берничә ысулы бар. Иң отышлысы, әмма вакыт буенча озаграгы (2–3 сәгать) – электричкада бару. Шулай ук монда «Казан – Киров» поезды белән барып җитеп була. Билет бәясе – 250 сум.

Арча районы
Кырлай турында кечкенәдән ишетеп беләбез, ләкин данлыклы авылны барып күрмәүчеләр бардыр әле. Русина Семененко монда бөек шагыйрь Габдулла Тукай эзләрен барлар өчен булса да килергә киңәш итә. «Музей белән танышкач, аның тирәсендәге парк буйлап йөреп килегез. Монда туристлар өчен барлык уңайлыклар да каралган. Искиткеч урман бар анда. Ә иң кызыгы – паркта бер үзенчәлекле нарат бар. Аны Габдулла Тукай үзе утырткан», – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Исәк җирлеге башлыгы Зөбәйдә Мөхәммәтҗанова шулай ди. Бу җирлеккә өч авыл керә: Әлки, Әнкәбә, Исәк. Җирлектә 493 кеше пропискада тора, яшәүчеләр саны – 341. Әле берничә ел элек кенә авыллары бетә дип торганнар. Мәктәпләре ябылган, кибетләренә йозак эләсе булганнар.

ЯШИБЕЗ ӘЛЕ!

– Эш булмагач, халык читкә китеп бетте, – ди җирлек рәисе. – Шөкер, хәзер бар да башкача инде. Авылыбызга Буа якташлык җәмгыяте җитәкчесе Ирек Закиров җан кертте. Мәктәп бинасында тегү цехы ачылды. Анда 11 авылдашыбыз эшкә урнашты. Кибетебез кабат эшли башлады. Әле безнең авылда кафе да бар. Анда бәйрәмнәр уздыралар.

Исәктә 2020 елда күркә фермасы эшли башлаган. Авылдашлары аның өчен Илдар Гыймаловка рәхмәт укый. Ул фермада бройлер тавыклар да үстерәләр. 8 хатын-кыз шунда эшле булган. Әле күптән түгел генә сыер фермасы ачканнар. Анысы Рәмис Хәсәнҗановныкы икән.

Кибетләре дә шәһәрнекеннән ким түгел. Җаның ни тели – шул бар. Кафеда пешерелгән камыр ризыкларын да кибетче Эльмира Дәүләтшина сата икән.

– Кафеда эшләүчеләр әле генә кайтып китте. Кайнар пироглары бар. Ниндиен бирим? – ди сатучы.

Монда пешкән ризыкны тиз алып бетерәләр икән. Ярымфабрикатларны да сорап кына торалар, ди.

– Авыл кешесе районга барып йөрмәсен өчен, барлык кирәк әйберне кайтартабыз. Ипине көн дә китереп торалар. Безнең кафе кызлары пешергән пирогларны күрше авыллардан, Чувашиядән дә килеп алып китәләр. Авыл терелгәнгә сөенәбез. Без моның өчен Ирек абыйга рәхмәтле. Бөтен кешене уйлаган ул. Күпме эшсез яшьләрне ашлы итте. Балалар мәйданчыгы да ясатып куйды. Аңа рәхмәттән башка сүз юк, – ди кибетче.

Ирек Закировны туры китерә алмадык без. Соңыннан телефон номерын табып шалтыраткан да идек. Тик ул сөйләшергә теләмәде. «Сөйләрлек эш эшләмәдем әле», – дип чикләнде.

Үзе тыйнак булса да, ике авыл халкы да бары аны гына сөйли. Дөрестән дә, авылда ут сүнмәү – бәхет бит ул! Яшәсен генә! Кибетләре гөрләп эшләп тора, мәдәният йортларында бәйрәмнәр уза. Бүген эшсез өйдә ятучылар юк. Һәр йорт саен бишәр сыер асрыйлар. Сөтне килеп җыялар. Бакчалар да буш тормый монда. Маллар өчен чөгендер утырталар, печән чәчәләр икән.

Күтәренке кәефле авыл кешеләрен күптән очраткан юк иде инде. Шатлыклары эчләренә сыймый аларның. Кешегә авылы кирәк шул. Үзебез дә ял җиткәнен көтеп кенә торабыз бит...

ТӨЗӘЛМӘС ЯРА

Исәк авыл җирлегенә караган Әлкигә дә кереп чыктык. Гөлсем апа белән Фирдүс абый Сөнгатуллиннар турында күп яздылар инде. Кызлары вафат булгач, аның дүрт баласын үзләренә алып үстергән алар.

Алар үз балаларын каршылаган кебек каршы алдылар. Шулкадәр ачык, кунакчыл, киң күңеллеләр. Дүрт бала: бер кыз, өч малай үстергәннәр, тик бер кызлары якты дөньядан китеп барган. 12 ел узса да, яраларыннан кан саркый әле.

– 42 яшендә дүрт сабыен ятим итеп, туган көнендә үлеп китте ул, – дип сүз башлады Фирдүс абый. – Шуннан соң дүрт оныкны үзебезгә алдык. Безнең киявебез дә алтын бәясе кеше иде. Ишеткән булгансыздыр инде, моннан 20 ел элек Буада өч полиция хезмәткәрен атканнар иде бит. Берсе безнең Гамил иде аның. Кызым өч бала белән тол калды. Ире үлгәч, аны башка ир-ат белән таныштырдылар. Матур гына яшиләр иде. Уртак балалары да туды. Тик кызым кечкенә сабыена 2 яшь чагында үлеп китте. Аның йөрәге авырткалый иде. Үләсе көнне табиб та чакыртканнар, тик ул хастаханәгә бармаган. Әнә шулай итеп, дүрт бала ятим калды.

Фирдүс абый белән Гөлсем апага ул чакта балаларны бирәсе дә булмаганнар. Ятимнәр йортына алып китәрләр дип курыкканнар. Бигрәк тә кечкенә оныклары өчен борчылганнар. Әтисе, бертуганнарыннан аерылмасын, әби-бабасында яшәсен дип, баладан баш тарткач, калдырганнар.

– Кызымның олы улы Илнур да – әтисе кебек полиция хезмәткәре. Өйләнде инде. Кызы Энҗе Яшел Үзәндә киявдә, Гөлназыбыз Мари Илендә яши. Ул да тормышлы. Кечкенәбез Айгөлгә 15 яшь кенә тулды әле. Безнең янда. 8 нчедә укый. Анысы бигрәк җәл булды. Олыраклары әниләренең юклыгын аңлыйлар иде. Елап интектермәделәр. Ә менә Айгөлгә әнисез кыен булды. Әле ул әнисе үлгәндә имә иде. Миннән ими таптырды. Идәнгә аунап елый иде сабыем. Бергә еладык, – ди Гөлсем апа.

Гөлсем апаның төшенә кызы Резеда бер генә тапкыр кергән. Кызының кулында ике пакет икән. Берсендә – хөрмә, икенчесендә – җимеш. Резеда аның берсен – әнисенә, икенчесен энесе Фәнискә бирә.

– Ризалыгын белдерүе булгандыр инде. Фәнис апасының каберен карап кына тора. Балаларга да терәк булды, – ди Гөлсем апа. Шулай диде дә елый башлады. Фирдүс абый да яшен тыя алмый. Оныкларга сөенеп кенә онытылып торабыз, ди алар. Фирдүс абый тракторда эшләгән, соңгы елларда фермада мөдир булган. Сиксәнне тутырса да, йөгереп кенә йөри әле. Ә 42 ел сыер сауган Гөлсем апаның аяклары авырта.

Сөнгатуллиннарның өч улы да үз тормышлары белән яши. Икесе – Казанда, төпчекләре Фәнис Буада икән. Гөлсем апа кечкенәсен 37 яшендә тапкан. Хәзер менә сөенеп туя алмыйм, ди.

– Без картаймый, кем картайсын, эт тә картайды инде. Шарикка да 12 яшь тулды, – ди Фирдүс абый этен яратып. Ә аннары үзенең яшьлеген сагынып: «Әле кайчан гына сайлау комиссиясе рәисе идем. Ничә еллар буе төнгә кадәр клубтан чыкмадым», – дип уфтанып куйды...

Шөгыль

Алтын куллы Илгизәр

Буада яшәүче агач остасын әнә шулай дип йөртәләр. Илгизәр Садарытдиновның кулыннан килмәгән эше юк. Өйләрендә бер җиһаз да сатып алынмаган, хуҗа барысын да үз куллары белән ясаган. Бала бишеге дә, кухня гарнитуры да, карават, шкафлар, спорт җиһазларына кадәр агачтан.

– Кул эшенә кечкенәдән әтием өйрәтте. Ул чакта әле электр кораллары да юк иде. Гел кул хезмәте булды. Хәзер генә рәхәт ул. Җаның ни тели, шуны ясап була. Әмма элек тә тик тора белмәдек. Агачтан куна такталары ясап, базарга барып сата идек. Аннары шул акчага киногa керә идек. Эшләп үстек, – ди Илгизәр абый.

Яшьлегендә Казанда яшәргә дә туры килә аңа. Шул вакытта да агач эшен туктатып тормый. Ә инде авылда яши башлагач, бөтенләй «җенләнә». Әле күптән түгел генә өй эчләрен такта белән тышлаганнар. Шул вакытта хатыны Фәридә апаның да ярдәме кирәк булган. Берсе кисеп тора, икенчесе агачны ышкып шомарта икән. Йорттагы бер такта да буялмаган. Барысы да нараттан. Аларны махсус пропитка белән генә каплаганнар. Шулай иткәндә, ул хуш исле булып тора, ди.

– Иремнең кулы алтын. Нинди эшкә тотынса, шуны башкара, – ди Фәридә апа. – Биле авырта башлагач, физик күнегүләр ясарга куштылар. Аптырап тормады, спорт җиһазы ясады да куйды. Хәзер көн дә иртәбез зарядкадан башлана. 70не тутырсак та, бер дә картаясы килми әле. Иремне эшсез тотып булмый. Остаханәсендә көнозын эштә ул. Сораучылар булса, бишек тә ясый, әле менә бакчабызга матурлык өчен күярга дип, тегермәнгә тотынды. Аны башкарып чыгасы бар.

Садарытдиновлар җырга-моңга да гашыйк икән. Җырлыйлар да, төрле бәйгеләрдә дә катнашалар. Фәридә апа «Гөлҗамал» ансамбленә йөри, Илгизәр абый ясаган кул эшләре белән күргәзмәдән кайтып керми икән. Өйләрендә татулык, мәхәббәт аларның. Бер-берсен аңлап яшиләр. Берсе кадак тотса, икенчесе чүкечкә үрелә.

– Иремә рәхмәтлемен. Нинди әйбер кирәк дип әйтсәң, шуны ясап куя. Мин гел аптыратам инде үзен. Хатын-кызга күп кирәк бит. Киштәсен дә ясатам, урындыгын да, тәрәзәсен дә. Ә ул бик теләп эшләп куя, – ди Фәридә апа.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«БИЕКЛЕККӘ ТАРТЫЛАМ...»

ИСЛАМИЯ МӘХМҮТОВА ИҖАТЫНА ШТРИХЛАР

Бу исемне атагач, колакта «Кыр казлары артыннан» җыры яңгырый башлый. Юкса йөзәрләгән роль башкарган, иҗатта үзен төрле яктан ачкан шәхес ул. Без иҗатташ дуслары, туганнары, гаиләсе белән «Кыр казлары артыннан» спектакленең уңыш сәбәпләре, әлеге спектакль аша Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Исламия МӘХМҮТОВА шәхесенең кайбер якларын ачтык.

Көрәшче

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рузия Мотыйгуллина өчен апасы Исламия Мәхмүтова – барыннан да бигрәк, көрәшче:

– Тормыш – үзе көрәш. Кеше әгәр шушы тормышта көрәшә икән, нәрсәгәдер ирешә ала, көрәшми икән, юкка чыга. Исламия апа исә бервакытта да агымга ияргәнде, киресенчә, каршы бара иде. Бу сүзләрне раслар өчен, бер вакыйганы искә төшереп үтәсем килә. Академия театры күченеп киткәч, бушап калган тарихи бина турында бик күп сүз булды, төрле фикерләр яңгырады. Алар арасында «бу бина күчмә театрга калырга тиеш» дигәне дә бар иде. Ник дигәндә, күчмә театрның үткән юлы, абруйлы тарихы бар. Ләкин берзаман бинаны башка оешмага бирүләре турында хәбәр килеп ирешә. Исламия апа аптырап калмый, беркемгә керми, хәбәр итми – иртән бер төркем егетне ияртеп, Мәскәүгә чыгып китә. Мәскәүдә сине кем белә дә, син кемгә кирәк инде анда, бер караганда. Алар ничек итсә иткәннәр, үз дигәннәренә ирешкәннәр, бинаны күчмә театрга бирү карарын Казанга алып кайтып җиткергәннәр. Исламия Мәхмүтова шушы гамәле белән үз исемен театрның тарихына алтын хәрефләр белән язып калдырды.

Аның асыл сыйфатларының берсе – гадел булуы. Ул ялагайлыкны, куштанлыкны, кеше сөйләүне бервакытта да кабул итмәде, һәрвакыт түбәнчелек итеп саный иде.

Исламия апа, яшь артистлар эшсез утырса да, көенә иде. Холкы эзләнүчән, йөрәге батыр булганга, пьесалар яза башлады, театр яшьләрен эшле итте. Артистлар аны әле дә, безне үстерде, дип искә ала. Шуңа мин аны шәхес дип кенә калмыйм, бөек шәхес дип әйтәм.

Мин – аның сеңлесе. Исламия апа бик туган җанлы, киң күңелле кеше иде. Кечкенәдән артист булырга хыялланып, авылдан чыгып киткән, күчмә театрны эзләп тапкан, һөнәргә төшенгән, сәхнәдә үз урынын тапкан. Ә без әзергә килдек. Җизни белән апа мине үз балаларыдай күрделәр. Театр училищесына укырга керергә дә Исламия апа белән бардым. Театр дөньясына кереп китү җиңел булды. Гомумән, Исламия апа 18 квадрат метрлы фатирларына бөтен туганын сыйдыра алды. Туганнары, туганнарының балалары – кемгә урын кирәк, Исламия апаларга килде. Хәлил абый да, Исламия апа да ачык күңелле булдылар. Минем театр юлыннан китүемдә дә, уңышларымда да аларның өлешләре зур.

Ул – халыкныкы

Татарстанның халык артисты Илгизәр Хәсәнов фикеренчә, уңыш сере – артистның халык арасыннан булуында:

– Мин театрга 1980 елда килдем. Ул вакытта Исламия апа Татарстанның атказанган артисты иде инде, ләкин шул вакытта ук халык артисты дәрәҗәсенә күтәрелде. Чөнки сиксәненче елларда Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» спектакле бара иде. Ясминә роле белән халыкныкы булды Исламия апа.

Без төрле шәһәрләрдә булдык, авылларда йөрдек. Спектакль тәмамланганнан соң, пәрдәне ябарга кирәк – яптырмыйлар. Исламия апа сәхнәдән кереп китә алмый иде.

> Теләсә кайсы спектакльдән соң, гозерләп, шушы җырны башкаруын сорыйлар иде. Артистның төрле чагы була, Исламия апаның да сәхнәгә авырган килеш чыккан вакытлары еш булды. «Бүген тавышым юк шул, җырлый алмыйм», – дисә, «Син акрын гына җырла, без барыбер тыңлыйбыз», – дип әйтәләр иде. «Кыр казлары артыннан» җырын башкалар җырлаганны да күп тыңладым. Барысы да дөрес җырлый, ләкин берсе дә Исламия апа кебек Ясминәнең эчке халәтен җиткерә алмый.

Бу образга бәйле рәвештә кызык хәлләр дә булгалады. Мәгълүм булганча, Хәлил абый спектакльдә аның ирен – Маликны уйнады, Исламия апа – Ясминә. Авылларда квартирга аларны бергә кертәләр иде. Исламия ападан еш кына хуҗалар, ничек торасың син бу ир белән, дип тә сораганнар.

Ясминә аңа күк капусын ачты

Татарстанның халык артисты Нуретдин Нәҗмиев аңарда ирләр холкы иде дип искә алды:

– 1976 елны Минзәләдән Казанга кайттым. Шуннан бирле аның белән бергә эшләдек. Хәер, аңарчы да, 1968 елдан бирле дуслар идек, хәл-әхвәлне белешеп яшәдек, ә инде бер казанда кайный башлагач, гаилә дусларына әверелдек. Аның белән бергә уйнаган беренче спектакль – «Онытылмас бәет» булды. Мин – Ак баба, ул героиня иде. Аннан «Кайту», аннан бер-бер артлы башка спектакльләр туды. Сәхнә партнеры буларак, ул ышанычлы иде. Берәр нәрсә килеп чыкмаса, зарланабыз, чәпчибез бит инде, шул чакны ул безне тынычландыра, күңелгә канат куя белде. Юлда да рәхәт кеше Исламия. Бервакытта да төшенкелеккә бирелмәде. Берзаман буранда адаштык, күңелгә шом керде, барыбыз да пошаманга калдык. Бер Исламия шушы хәлдән кызык табып көлә, шул арада вазгыятьне үз кулына алды.

Үзе язган «Күрәсем килгән иде» спектаклендә бергә соңгы тапкыр уйнадык. Шуннан аның белән очрашып булмады. Мин аңа: «Нихәл, маманя?» – дип шалтырата идем. Рәхәтләнеп көлә дә үз яңалыкларын сөйләп китә иде. Ә бит Ходай аңа бөтен сәләтне өеп биргән. Ул – талантлы артист та, драматург та, режиссер да. Авылларга гастрольгә барсак, халык иң беренче, Исламия бармы, килдеме, дип сорый. Исламия булса, спектакль аншлаг белән үтә.

Аңа күк капусы «Кыр казлары артыннан» спектаклендә ачылды, дип уйлыйм. шушы спектакльдән соң, кайсы гына спектакльне уйнасак та, соңыннан Исламиядән «Кыр казлары артыннан» җырын башкаруын сорыйлар иде.

Нуретдин абый үкенечен дә искә алды:

– Исламия белән бәхилләшә алмый калдым. Юкса кызы Лилия, шалтыратып: «Нуретдин абый, килә алсаң, кил, яме, сине күрәсе килә», – дип хәбәр иткән иде. Нәрсәдер килеп чыкты, бара алмадым. Икенче көнне вафаты турында хәбәр алдым. Үлем үкенечсез булмый инде... Бәлкем шулай кирәк булгандыр.

Мәхмүтовлар театры

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Зөфәр Харисов, бу гаиләне театрның нигезе, диде:

– Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» пьесасы Равил Тумашев куелышында премьера көнне үк бик зур уңыш казанды һәм дистә еллар репертуардан төшмәде. Халыкның иң яраткан спектакле, Тинчурин театрының визит карточкасы иде ул. Аның уңышы нәрсәдә соң? Бу – өч йолдызның бергә туры килүендәдер. Беренчедән, пьесаның авторы – иң нечкә күңелле шагыйрь һәм иң көчле әдип. Икенчедән, әсәргә музыканы иң моңлы җырлар авторы Мәсгуть ага Имашев язган. Өченчедән, халыкчанлыгы белән тамашачы мәхәббәтен иҗатының башында ук яулаган Исламия Мәхмүтованың Ясминә ролен башкаруы. Йөрәктән чыккан йөрәккә барып җитә, диләр бит. Бу очракта да өч шәхеснең ихлас иҗаты бәрәкәтле җимешен бирде. Хәтеремдә әле, спектакль репертуардан алынган иде инде, Исламия апага Хәтер көнендә «КамАЗ» машинасы арбасында Сөембикә образында барырга кушылды. Ирек мәйданыннан Казан Кирмәненә кадәр юлны сүзсез-нисез үтсә. Халык Исламия апаны танып алды да, «Кыр казлары...»н җырла әле, дип сорый башлады. Бу хәл гастрольләрдә дә еш кабатлана иде. Себер якларында «Сынган беләзек»не уйнадык берзаман. Спектакль беткәч, халык таралышмады, алкышлар белән Исламияне чакырып, шушы җырны башкаруын үтенде.

> Аның Тинчурин театрындагы роле бәһаләп бетергесез. Исламия апаның көче, сәләте Тинчурин театрын татар дөньясына, Россия киңлекләрендә танытты. Рәсми рәвештә театр Тинчурин исемен йөртсә дә, халык өчен ул – Мәхмүтовлар театры, Исламия Мәхмүтова театры булды. Халык аңа йөрде, ул язган пьесалар үзешчән театрларны туендырды.

Мин исә аның белән якыннан аралашуыма, бер «подружкасы» булуыма бик сөенәм. Чөнки ул миңа сәнгатькә аек акыл белән һәм җитди карарга өйрәтте, бервакытта да алдарга ярамаганлыгын аңлатты. Тамашачы каршында син ихлас булырга тиешсең, ясалма булма, дип өйрәтте. «Син бит – минем бергенәм» спектакленең беренче куелышында миңа Сабир ролен бирде. Анда кызы Лилия

белән мәхәббәт уйнарга кирәк иде. Шунда мине, кыйный-кыйный, сәхнәдә яратырга өйрәтте.

«Исламия кызы»

Артист баласы булу җиңел түгел. Кызы, Татарстанның атказанган артисты Лилия Мәхмүтова әнә шулай ди:

– Мин, гомумән, әтисез, әнисез үстем дисәң дә була. Чөнки әни 8 айлык чагымда авылга кайтарып куйган да, 5 яшемә кадәр дәү әнидә, авылда үстем. Мәктәпкә барырга вакыт җиткәч, әтинең әнисе Сабира әби безнең белән яшәде. Октябрь айларында килә, апрель ахырларында авылына кайтып китә иде. Ул безгә: «Балалар, әти-әниегезне бөтен Татарстан белә, аларның йөзенә кызыллык китермәгез», – дип әйтә килде. Үсеп җиткәч тә, әнә шул кысадан чыкмадык. Ник дигәндә, без үскән саен, әти-әнинең дәрәҗәсе дә үсте. Хәзер инде үз балама да шул сүзләрне әйтәм.

Сәхнәгә беренче чыккан мәлләрдә залдан «Исламия кызы» дигәнне еш ишетә идем. Хәер, хәзер дә әйтәләр инде. Әни үзе язган «Мәхәббәт чишмәсе» спектакле театрда 13 ел барды. Анда мин дә уйнадым. Берзаман аны безнең кунаклар да карады һәм: «Кара, Исламия, кызың синнән дә уздыра бит», – дип мактадылар. Әни горурлыктан балкый иде шул чакта.

Ул – күпкырлы шәхес. 50 яшен уздыргач, илһамы килде һәм пьесалар яза башлады. Беренчесе «Син бит – минем бергәнәм» дип атала. Без аны беренче куелышында 14 ел уйнадык. Икенче куелышы театрда өченче ел бара. Аннан соң «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» пьесаларын язып, үзе сәхнәләштерде дә. Аларда минем өчен махсус рольләр язды.

> Ясминә образына килгәндә, Равил абый Тумашев аны бу рольгә билгеләгәндә, әнигә 35 яшь була. Ә бит Ясминә – 55 яшьлек хатын образы ул. Әни режиссерга олы хатын ролен биргәнгә үпкәләп тә йөри. Шулчак Равил абый аңа, бу – иң көчле образларның берсе булачак, дип әйтә. Юраганы юш килде, билгеле.

Заманга Ясминә кирәк

Әгәр «Кыр казлары артыннан» спектакле кабаттан куелса, Ясминә ролен кем башкарыр иде? Бу сорауга Лилия: «Мин үз өстемә андый җаваплылык алмас идем», – дип җавап бирсә, Ләйсән Мәхмүтова ул рольне бары тик апа гына башкара ала, дигән фикерен җиткерде:

– Ә бит күпме тамашачы әлеге спектакльнең сәхнәгә кабат кайтуын көтә! Яңартылып, күпме спектакль яңадан куела! Халык Лилия апаны Исламия Мәхмүтова дип кабул итә. Бер генә кимчелеге бар: ул үзенә бик тәнкыйди карый. Тик әлеге спектакльне яңартырга, халыкка яңадан кайтарырга кирәк. Хәния апа Фәрхине искә төшерегез. Аны халык ничек яратты. Хәния ападан соң кызы чыккач, аннан яраткан артистларының чалымнарын эзләделәр. Әнинең чалымнарын Лилия Мәхмүтова гына чыгара ала.

Миңа әти белән әни игътибары күбрәк эләкте. Алар белән гастрольләрдә дә йөрдек, барысын да күрдек, Аллага шөкер. Төпчек бала булгач, болар бит – шәхес дип уйлап, үземне нииндидер кысага кертергә тырышмадым. Вакыты да шундый бит: туксанынчы еллар үзгәртеп корулары иде. Ул чакта мине тәртә арасына кертүче Лилия апа булды. Берәр нәрсә ошамаса, тиз суыта иде. Аннан туарыларга вакыт та булмады. Бергәләп гөр килеп эшләп йөргән вакытлар. Әни, кайчак, борчылып: «Нәрсә уйныйсыз, миңа күрсәт әле», – ди. Мин исә: «Борчылма, чыгам да уйныйм», – дип әйтә идем. Тинчурин сәхнәсеннән китүемә амбицияләр сәбәпче булгандыр. Үземне төрле яктан сынап карыйсым килде. Рольләр дә бик аз иде. Булганы да өч сүзлек кенә. «ЗөЛәйЛә» триосы оешып, танылып барганда, массада йөрисе килми башлады. Без режиссер белән аңлашып аерылыштык.

Әни кино өчен дә яхшы артист иде. Тик ул вакытта Татарстанда әле андый мөмкинлек булмады. Әни чын мәгънәсендә талант иде.

Бер җыр белән танылган әсәрләр бар, ләкин күп түгел. Берсе Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә»се булса, Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан»ы – икенчесе. Аның Исламия Мәхмүтованы биеклеккә күтәрүе шиксез.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

«БӨЕКЛӘР ЭЗЕННӘН» СӘХИФӘСЕНЕҢ ВИДЕОСЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА (ХИКӘЯ)

СӨЕП, СӨЕЛЕП ЯШИСЕМ КИЛӘ!

< Дәвамы. Башы 15, 22 апрель саннарында

Башка парлар кебек, кеше күзе төшмәгән урыннарда йөриселәре килсә дә, түтәйнең ара-тирә ихатаны урап керү гадәте аларны ерак җибәрмәде. Шулай да, солдат хезмәтен үтәп кайткан егет шактый гына шомарган иде. Капка төбендәге баганадагы утны ул беренче кичне үк сафтан чыгарып, моңа кадәр егетләр белән йөрүдә бернинди тәҗрибәсе булмаган кызга назларын җәлләмәде. Ике атнадан соң, Маһинурны әтисе килеп алды. Кыз, иң беренче үбешкән кешесен исеннән чыгара алмый, кичләрен төрле хыялый уйларга чумып ятыр булып китте. «Менә килер, менә килер (авыл аралары утыз чакрым чамасы иде)», – дип көтә торгач, уку елы да башланды. Фәнис күренмәде. Кунактан кайткач, кызының берничә тапкыр яшьле күзләрен күреп калган әнисе, әлбәттә, эшнең нидә икәнен сизенә иде, чөнки түтәй серне бераз «тишкән» иде. Шулай да кызы үзе ачылып бармагач, төпченмәде. «Барыбызның башыннан үткән әйбер инде – беренче мәхәббәт Маһинурдан гына калмас», – дип уйлап куя да көндәлек тормыш мәшәкатьләренә кереп чума иде. Тик шулай да беркөнне кичкә таба, кызының кәефе юклыгын күргәч: «Быел имтиханнар елың, җегет уйларга яхшы билге куймаслар», – дип орышыбрак эндәште.

– Фффәниис?!

– Әйе, мин! Аптыраттымы әллә?

– Әлбәттә! Син милиционермыни?

– Шофер булып урнаштым әлегә, алда күз күрер.

– Аңлашылды-ы-ы. Димәк, безнең авылга эш белән килгәнсең.

«Минем янга түгел», – дип әйтергә уйлаган иде дә, тыелып калды. Фәнис аның уйларын укыгандай:

– Теге вакытта синең яныңа барырга җыенганымны түтәң белеп калган да: «Йөрмә, җаныңны алырмын!» – дип килеп җиткән безгә. Милициягә эшкә барырга ниятләп торган көннәремдә мондый сүз ишеткәч, уеннан уймак чыкмасын дип, ниятемнән кире кайттым. Язмыш булгач, менә тагын очраштык, чибәрем!

Җиде кат күккә менеп китәрдәй канатлар тагылган кеше кебек кайтып керде Маһинур өйләренә. Әниләре эштән кайтканчы дип, башта болай да ялт итеп торган өйне җыештырып, идәннәрне юып чыгарды. Иртәгәгә дип, токмач та кисеп куйды. Аннан дәресләрен карарга утырды. Тик күз алдына Фәнис килеп баса да, косинус белән синусны әдәбият дәресләрендәге шигърияткә чорный да куя. Тегеләй дә, болай да авызлыклап булмаган хисләр, Маһинурның күңелен рәхәтләнеп иләсләндерде. Бераздан, бөтенләе белән урамга ук алып чыгып

– Бик кирәкләре бар иде!

– Кирәкмәгәч, нигә һаман иманыңа оеп утырасың?

– Имтиханнарны уйлыйм.

– Уйлама, әзерлән. Үзең сигездән соң техникумга барам дисең, таныклыгында гел яхшы билгеләр генә булса, имтихансыз гына үтәчәксең бит.

– Унынчыны бетереп, институтка барасы килә.

– Бер атнада җиде җомга булыр инде синең! Әйткәнне аңла, соңыннан терсәгеңне тешләрдәй булмасын, вәт!

Хәдичә, көтү кайтыр вакыт җиткәнгә, шунда нөктәсен куеп, тышка чыгарга әзерләнә башлаган иде дә, кабат кире борылып, түр якка үтте.

– Кызым, син теге биремне онытмадыңмы?

– Нинди бирем?

– Таһирә апаларың турында.

– Юк, оныттым инде, мин бит иманыма оеп утырырга гына яратам.

– Ярар-ярар, төртмә телеңне кирәк вакытка калдыр! Яза барасыңмы?

– Язарлык бер нәрсә дә юк, трактор белән түгел, кул арбасы белән дә кергән кеше юк аларга.

– Бәлки, син карамаган чагында керәләрдер.

– Соң, әни, керсә керә инде, мәктәпкә йөрми, тәрәзәдән карап утыра алмыйм бит инде. Үзең беләсең, имтиханнар елы, тырышырга кирәк. Әйткәндәй, Таһирә апа минем тәрәзәдән аларны күзәткәнне сизә бугай, исәнләшкәнемне салкын гына ала башлады соңгы вакытларда. Әле озак күзәтергәме?

Хәдичә кызына ни дип тә җавап кайтарырга белмәде. Бәлки, ашлык таратып бетерергәнчедер?

***

«Таһирә өстеннән жалу язганнар» дигән хәбәр авылда таралганга да бер айга якын вакыт үтте. Тегеләй дә, болай да тикшергәннән соң, «Фактлар ачыкланмады» дигән кәгазьләр язылды. Тик өч айлап вакыт узгач, эшнең әчке эшләр органнарына барып җиткәне билгеле булды.

Тикшерүче яшь кеше иде. Районга килеп эшли башлавына да бер елдан гына артык вакыт үткән. Дөрес, укуын тәмамлагач, башкалада бер ел эшләгән, диделәр. «Тәҗрибәсе дә юк инде, нишләтеп бетерер бу мине», – дип, Таһирә бер яңы, бер көйде. «Гаебем юк ич минем, нигә куркырга тиеш әле? Колхоз рәисе дә, партком секретаре да, авыл советы да минем яклы, ревизия материаллары буенча бөтен эш тәртиптә», – дип уйларга тырышса да, күңеленең бер почмагы барыбер китек килеш торды. Шикаять язылганнан бирле юньләп төн йокысы күрмәгәнгә, бите суырылып ябыкса да, карынында инде җан кергән сабые булгач, гәүдәсендә ул-бу сизелмәде. Сабиры: «Бер гаепсезгә кем утыртсын?» – дип, хатынын да, үзен дә тынычландырып торса да, «Беркемгә аламалыгыбыз тимәде, кешедән артык җиребез юк, нахак бәла тагарга кемнең башына килде икән?» – дигән уйлардан тиз генә арына алмады.

***

– Маһинур!

Кыз: «Колагыма ишетеләме?» – дип уйлап бетермәде, милиция машинасы эченнән чыккан тавыш хуҗасы каршына килеп басты.

киттеләр. Фәниснең: «Кичке тугызлар тирәсендә авыл башына кил!» – дигән сүзен кабатлый-кабатлый, кыз шул якка таба атлады.

Алар йөз ел күрешмәгән кешеләр кебек күрештеләр. Көндез бер-берсенә якын килергә кыенсынып торсалар да, кичке караңгылык алар файдасына иде. Җәй көне ике атна гына булган очрашу аларны шактый гына якынайтып өлгергән булып чыкты. Назга сусаган иреннәр талымнарын басканчы үбештеләр. Беренче түйдым дигәч тә, тагын озаклап үбештеләр. Ике ай эчендә Маһинур да үзгәргән. Теге вакыттагы кебек, егетнең бөтен тәне буйлап йөргән кулларын инде алып куярга ашыкмый, йомшак куллары белән Фәниснең муеннан иркәләп кочаклый, күкрәгенә сарыла.

– Иртәгә дә килә бе з эш белән, озакка сузылыр, бик буталчык эш ди тикшерүче Сабиров.

– Нәрсә булган соң шулкадәр?

– Төгәл генә белмим, мин бит – алып килүче һәм алып кайтучы гына. Склад мөдиренә кагылышлы бугай.

– Таһирә апагамы?

– Склад мөдире булып Таһирә апагыз эшләсә, димәк, аңа кагылышлы булып чыга инде, чибәрем!

Маһинурның кинәт кенә кәефе төшкәнгә, Фәнис игътибар итми калмады.

– Әллә берәр туган тиешле кешегезме?

– Юк, күрше апа.

– Күрше – туганнан да якынрак кеше, дип әйтергә ярата минем дәү әни.

Маһинур эндәшмәде. Арадагы тынлыкка кочаклашу-үбешү ярдәмгә килде. Сагыну хисләре әле басылырга да уйламаган иде. Фәниснең куллары Маһинурның изүендәге төймәләрне җайлап кына ычкындыра башлады. Кыз: «Нәрсә эшләтсәң дә, ризамын», – дигән кебек, күзләрен йомды. «Их, кияүгә чыгасы иде дә, рәхәтләнеп сөйгәнең белән яшисе иде! Буйга озын, ыспай гәүдәле, чем-кара мыеклы Фәнистән да чибәррәк, акыллырак кешене башка очрата алмасына бөтен җаны-тәне белән ышанган кызны татлы хыяллардан, әнисенең үткән ел, унынчы сыйныфта укып йөргән кызның, алданып бала тапканын ишеткәннән соң әйткән сүзләре айнытып җибәрде: «Мин бала хакына кичерермен дә, бәлки, ләкин әтиең бәреп үтерәчәк!» Маһинур җәһәт кенә егетнең куенынан шуып чыкты да төймәләрен каптыра башлады.

– Нәрсә өркедең, мин «рамка»дан чыкмыйм, курыкма! Я инде, карышма. Әле тагын кайчан очрашабыз? Беләсеңме, мин сине беркемгә дә бирмим, үземнеке генә буласың, унсигезең тулу белән, яме, чибәрем!

– Өч ел көтәргә ризасыңмы? Син бит – хезмәттән кайткан егет, өйләнерсең дә куярсың әле башкага!

– Көтәм дип әйттем бит инде.

– Әбиләр әйтмешли, Аллаһ бирсә дип әйт.

– Бирсә дә, бирмәсә дә, көтәчәкмен!

Кайнар тын алышыннан, башны әйләндерерлек исерткеч сүзләрдән, иреннәр тагын бер-берсенә үрелделәр...

Дәвамы бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

П2435
җомга саны
488 сум 10 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1099 сум 32 тиен

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 майга кадәр газетага язылучылар арасында **тандыр һәм әфган казаны** уйнатабыз

Май ае өчен квитанцияләр 2022 елның 8 июненә кадәр кабул ителә. Бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июлена хәтле дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе
Тулырак: vatantat.ru

16+

Реклама

СТРОИТЕЛЬНАЯ БРИГАДА *Выполним все виды строительных работ с нашим материалом*

Строим дома, веранды, душ, хозблоки, беседки, бани, заборы, дорожки, красим дома, кладем печи, кафельную плитку. Подъем дач, ремонт крыш, заливка фундамента. Обшивка сайдингом, внутренние работы, делаем демонтажи.

тел.: 8 917 292 71 65 **Пенсионерам – скидка!**

Реклама

Сканворд клетках язылган сораулар:

- Кебек, шикелле
- ... һәм Пожарский
- Россиядәге өлкә үзәге
- ... - Лукойе
- Африкадагы ил
- Италия йөк автомобиле
- Нарат сагызы
- Отеллоның милләте
- «Меган», «Дастер»
- Шоколад
- Чиләбе өлкәсендәге шәһәр
- Грек мифологиясендә гайбәт алласы
- Тугыз башкаручыдан торган ансамбль
- Җырчы ... Броневицкая
- Сүс бирә торган тропик үлән
- Иң борынгы язма
- ... борчасы
- Париж аэропорты
- ... Фон Бисмарк
- Кәрим Тинчурин драмасы
- Төрле төстәге
- Бик нәфис, үтә күренмәле чигеш
- Әдәби әсәрнең төп эчтәлеге, сюжет сызыгы
- Дөньяга килү
- Шикәрне алыштыра торган матдә
- Уфада татар телендә чыгучы яшьләр газетасы
- Тын океандагы утрау
- Шобага
- ... Җиһанша
- ... Ширак
- ...-мачта
- ...-клуб
- Сербия каласы
- Амудәрьяның борынгы исеме
- Япон оекбашы
- Бозауламый калган сыер

Рәис Габдулла

22 апрель санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: каноэ, туку, Зураб, чар, Еники, кабат, үтүк, әйтик, әл, кагор, әрлән, сүрү, Ногман, бриз, кешью, үтә, тозак, ничә, кале.
Вертикаль буенча: тәбәнәк, кузак, ро, Акура, тәлгәш, Нур, иләм, Арк, юнан, эрбет, тик, ас, оча, интегү, Рүзәл, орбита, искерү, Зәки.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Наполеон сугышлары ничәнче елларга туры килә?
А) 1700–1721;
Б) 1799–1815;
В) 1812–1830.

2 Казанда «Милләт» исемле нәшриятны оештыручыларның берсе.
А) Галимҗан Ибраһимов;
Б) Шиһабетдин Мәрҗани;
В) Галимҗан Баруди.

3 Эсерлар партиясе кайчан оеша?
А) 1800;
Б) 1905;
В) 1902.

4 1912, 1915 елларда татар театрының тагын ике труппасы «...» һәм «...» төзелә.
А) «Нур», «Ширкәт»;
Б) «Нур», «Әл-гасрел җәдит»;
В) «Таң», «Нур».

5 «Үлеммени безгә үкенечле,
Халкың өчен булса үлемең?
Күтәрәлмим, дуслар, мин хурлыгын
Ачтан шулай егылып үлүнең».
Бу шигырь юллары авторы кем?
А) Муса Җәлил;
Б) Роберт Миңнуллин;
В) Рифат Сәлах.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) В; 4) А; 5) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 261

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+